СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

« 23» апрель 2021 ел №20

**Яңа Кишет авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**
**Яңа Кишет авыл җирлеге Уставын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 нче статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 нче елның 28 нче июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы статьясы нигезендә Яңа Кишет авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын кушымта нигезендә расларга.
2. Яңа Кишет авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 27 нче октябрендәге 97.1 номерлы «Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге уставын раслау турында» гы карарын 2015 нче елның 30 нчы июнендәге 16 нчы номерлы, 2015 нче елның 26 нчы октябрендәге 7 нче номерлы, 2016 нчы елның 1 нче ноябрендәге 17 нче номерлы, 2017 нче елның 11 нче маендагы 5 нче номерлы, 2018 нче елның 8 нче маендагы 3 нче номерлы, 2018 нче елның 7 нче сентябрендәге 6 нчы номерлы, 2019 нчы елның 9 нчы октябрендәге 35 нче номерлы, 2020 нче елның 14 нче апрелендәге 48 нче номерлы үзгәрешләре белән үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Яңа Кишет авылы, Дуслык урамы, 100а йорты, Иске Кишет авылы, Г.Сафиуллин урамы, 26а йорты, Кышкар авылы, Яңа урам, 125 нче йорт, Симетбаш авылы, Үзәк урам, 19а йорты.
4. Әлеге карарны ул кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә Уставларны теркәү һәм дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органының территориаль органына җибәрергә.
5. Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгына Уставларны теркәү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан кергән көннән җиде көн эчендә "Яңа Кишет авыл җирлеге Уставын раслау турында"гы карарны халык күпләп җыела торган урыннарда урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында "Район җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.
6. Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгына рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн эчендә Уставларны теркәү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының территориаль органына уставны раслау чыганагы һәм раслау датасы турында белешмәләр җибәрергә.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Э.Ф.Минзянова

*Яңа Кишет авыл җирлеге*
*Советының 23 апрель 2021ел,*
*№20 карары белән расланган*

## I бүлек. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### 1 статья. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең исеме һәм хокукый статусы

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге авыл җирлеге статусына ия.

2. Муниципаль берәмлекнең рәсми исеме – Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кишет авыл җирлеге» (алга таба текст буенча - Җирлек).

3. «Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы составына керә.

### 2 статья. Җирлекнең территориаль төзелеше

1. Җирлек территориясе составына Яңа Кишет авылы, Иске Кишет авылы, Кышкар авылы, Симетбаш авылы торак пунктлары керә.

2. Җирлекнең административ үзәге - Яңа Кишет авылы.

3. Җирлек чикләре "Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән.

4. Җирлек территориясе составына җирләр милек рәвешләренә һәм максатчан билгеләнешенә карамастан керә.

5. Җирлек чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору Татарстан Республикасы законы белән законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

### 3 статья. Җирлектә гражданнарның җирле үзидарәне гамәлгә ашыру хокукы

1. Җирлектә җирле үзидарә Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан җирле референдумнарда, муниципаль сайлауларда катнашу юлы белән һәм турыдан-туры ихтыяр белдерүнең башка рәвешләрендә, шулай ук әлеге Уставта каралган сайлау һәм җирле үзидарәнең башка органнары аша гамәлгә ашырыла.

2. Гражданнар җирле үзидарәне гамәлгә ашыруга турыдан-туры, шулай ук үз вәкилләре аша җенесе, расасы, милләте, теле, чыгышы, мөлкәти һәм вазифаи хәле, дингә, инанулары, җәмәгать берләшмәләренә каравына бәйсез рәвештә тигез хокуклы.

Җирлек территориясендә даими яки нигездә яшәүче чит ил гражданнары җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясенең халыкара килешүләре һәм федераль законнар нигезендә хокукларга ия.

3. Һәркем җирле үзидарә органнарына һәм вазыйфаи затларга турыдан-туры мөрәҗәгать итәргә, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат алырга хокуклы.

4. Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары һәркемгә аның хокукларына һәм ирекләренә турыдан-туры кагылучы документлар һәм материаллар белән танышу, шулай ук, әгәр законда башкача каралмаган булса, гражданнар тарафыннан җирлекнең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында башка тулы һәм дөрес мәгълүмат алу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

5. Җирле үзидарә органнары массакүләм мәгълүмат чаралары аша һәм башка ысул белән халыкка Җирлек һәм аның аерым территорияләрен үстерүнең иң мөһим мәсьәләләре, гомуми файдаланудагы транспорт, торак-коммуналь хуҗалык эше, халыкка төрле хезмәтләр күрсәтүче социаль-мәдәни һәм башка учреждениеләр һәм хезмәтләр челтәрен үстерү, социаль ташламалар турында, җәмәгать тәртибен саклауның торышы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр турында даими мәгълүмат бирәләр.

6. Гражданнар, оешмалар, әгәр аларның хокуклары һәм ирекләре бозылган дип санасалар, җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) судта дәгъва белдерергә хокуклы.

**4 статья. Җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасы**

1. Җирле үзидарә органнары структурасына Җирлек Советы, Җирлек башлыгы, Җирлекнең башкарма комитеты, әлеге Устав нигезендә төзелә торган башка җирле үзидарә органнары керә.

2. Җирлек җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртү әлеге Уставка үзгәрешләр кертү юлы белән гамәлгә ашырыла.

**5 статья. Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре**

1. Җирлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә түбәндәгеләр керә:

1) Җирлек бюджеты проектын төзү һәм карау, җирлек бюджетын раслау һәм үтәү, аның үтәлешен тикшереп тору, җирлек бюджеты үтәлеше турында хисап төзү һәм раслау;

2) Җирлекнең җирле салымнарын һәм җыемнарын билгеләү, үзгәртү һәм юкка чыгару;

3) Җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәтне биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү;

4) Җирлек торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

5) Җирлек халкын элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

6) Җирлектә яшәүчеләрнең ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

7) Җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлектә рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

8) Җирлекнең архив фондларын булдыру;

9) Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшереп тору, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерү оештыру;

10) адрес бирү кирәк булган объектларга адрес бирү, адресларны үзгәртү, юк итү, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге юлларыннан тыш) исемнәр бирү, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, әлеге исемнәрне үзгәртү, юк итү, мәгълүматны дәүләт адреслар реестрында урнаштыру;

11) авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүдә ярдәм итү, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру;

12) Җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

13) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

14) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортировкалау эшчәнлеген оештыруда катнашу;

15) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту;

16) Җирлек чикләрендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

17) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл эшчәнлеге;

18) милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) низагларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

19) Җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле керүен тәэмин итү дә керә;

20) үзбелдекле төзелгән корылманы җимерү турында Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә карар кабул итү, үзбелдекле төзелгән корылманы җимерү яисә аны капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына туры китерү турында карар кабул итү.

2. Федераль законнар нигезендә Җирлекнең җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Җирлек бюджетыннан муниципаль район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән аларга җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында килешүләр төзергә хокуклы.

### 6 статья. Җирлекнең җирле үзидарә органнары җирлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итүгә хокуклары

1. Җирлекнең җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Җирлек музейларын оештыру;

2) Җирлектә нотариус булмаган очракта, законнарда каралган нотариаль гамәлләр кылу;

3) опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруда катнашу;

4) Җирлек территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

5) Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә ярдәм күрсәтү һәм җирлек территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру;

6) Җирлек территориясендә урнашкан муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү чараларын оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

7) муниципаль янгын сагы булдыру;

8) туризмны үстерү өчен шартлар тудыру;

9) кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контролен гамәлгә ашыручы һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга булышлык күрсәтүче иҗтимагый күзәтү комиссияләренә ярдәм күрсәтү;

10) «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук инвалидларның гомумроссия иҗтимагый берләшмәләре оешмалары тарафыннан төзелгән оешмаларга ярдәм күрсәтү;

11) торак законнары нигезендә муниципаль торак фондыннан социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарга торак урыннары бирү;

12) Җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эш итүне гамәлгә ашыру;

13) "Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында" 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру;

14) инвалидлар, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затларга адаптив спорт, адаптив физик культураны үстерүгә ярдәм күрсәтү;

15) "Кулланучылар хокукларын яклау турында" 1992 елның 7 февралендәге № 2300-1 Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.

16) участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр әлеге вазыйфаны биләгән вакытка торак урыны бирү;

17) алкоголь, наркотик яки башка токсик исереклек хәлендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.

2. Җирлекнең җирле үзидарә органнары әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән мәсьәләләрне хәл итәргә, башка дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашырга хокуклы (аларга "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә тапшырылмаган), әгәр бу федераль законнарда каралган булса, шулай ук Җирлек бюджеты керемнәре исәбенә, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән бюджетара трансфертлардан һәм түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәреннән тыш, башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары компетенциясенә кермәгән һәм федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән аларның компетенциясеннән төшереп калдырылмаган башка мәсьәләләрне хәл итәргә хокуклы.

**7 статья. Муниципаль күзәтчелек (контроль)**

1. Җирле үзидарә органнары җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча кабул ителгән муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәүне, ә тиешле контроль төрләре федераль законнар белән җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән очракта, шулай ук федераль законнарда, Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән таләпләрнең үтәлешенә муниципаль контроль оештыралар һәм гамәлгә ашыралар.

2. Юридик затларга, шәхси эшкуарларга муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга, тикшерүләр үткәрәгә һәм уздыруга бәйле мөнәсәбәтләргә карата "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

**8 статья. Җирлекнең муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы**

Җирлекнең муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы җирле үзидарә турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

**9 статья. Җирле үзидарә органнарының дәүләт хакимияте органнары белән үзара мөнәсәбәтләре**

Җирле үзидарә органнарының дәүләт хакимияте органнары белән үзара мөнәсәбәтләре түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) Җирлекнең җирле үзидарә органнарының Җирлекнең социаль-икътисадый үсешенә юнәлдерелгән дәүләт программаларын гамәлгә ашыруда катнашуы;

2) Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хакимияте органнары арасында шартнамәләр (килешүләр) төзү;

3) даими яисә вакытлыча координация, консультация, киңәш бирү һәм башка эш органнары булдыру;

4) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Җирлек Советының закон чыгару инициативасы;

5) законнарда билгеләнгән үзара мөнәсәбәтләрнең башка рәвешләре.

**10 статья. Муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу**

Җирлектә муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу, муниципаль хезмәт вазыйфаларына таләпләрне дә кертеп, муниципаль хезмәткәрнең статусын билгеләү, муниципаль хезмәтне үтү шартлары һәм тәртибе "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге N 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы һәм Җирлекнең муниципаль хокукый актлары буенча гамәлгә ашырыла.

## II бүлек. ХАЛЫК ТАРАФЫННАН ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕ ТУРЫДАН-ТУРЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ҺӘМ ХАЛЫКНЫҢ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУДА КАТНАШУ ФОРМАЛАРЫ

### 11 статья. Җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда халыкның турыдан-туры катнашуы

Җирлек халкы җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыра һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда түбәндәге рәвешләрдә катнаша:

1) җирле референдум;

2) муниципаль сайлаулар;

3) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затын чакыртып алу буенча тавыш бирү;

4) Җирлек чикләрен үзгәртү һәм үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү;

5) гражданнарның хокукый инициативасы;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә;

7) гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар;

8) гражданнар җыелышы;

9) гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы);

10) гражданнарны сораштыру;

11) җирле әһәмияттәге аеруча мөһим мәсьәләләр буенча халык фикер алышуы

12) гражданнарның җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгатьләре;

13) гражданнар җыены;

14) инициатив проектлар;

15) Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка формалар;

Җирле үзидарә органнарының муниципаль милектәге предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар белән, шулай ук физик затлар белән мөнәсәбәтләре, законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, шартнамә нигезендә төзелә.

### 12 статья. Җирле референдум

1. Җирле референдум җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә турыдан-туры халык тарафыннан хәл итү максатларында уздырыла.

2. Җирле референдум "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законда һәм "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып үткәрелә.

Җирле референдумда катнашу өчен гражданнарның хокуклары гарантияләре, шулай ук җирле референдумны әзерләү һәм уздыру тәртибе федераль закон һәм "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнә.

3. Җирле референдумда яшәү урыны Җирлек чикләрендә урнашкан Россия Федерациясе гражданнары катнашырга хокуклы. Россия Федерациясе гражданнары җирле референдумда гомуми тигез һәм турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә яшерен тавыш бирү юлы белән катнаша.

4. Җирле референдумны уздыру турындагы карар Җирлек Советы тарафыннан түбәндәге инициатива буенча кабул ителә:

1) җирле референдумда катнашу хокукына ия гражданнар;

2) уставларында сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда катнашу каралган һәм федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта теркәлгән сайлау берләшмәсе, башка иҗтимагый берләшмә;

3) Җирлек Советы һәм Җирлек башлыгының бергә күрсәткән инициативасы;

5. Гражданнар, сайлау берләшмәләре, башка иҗтимагый берләшмәләр инициативасы буенча җирле референдум билгеләү шарты булып әлеге инициативаны хуплап имзалар җыю тора, аларның саны Җирлек территориясендә теркәлгән референдумда катнашучылар санының биш процентын тәшкил итәргә тиеш, ләкин 25 имзадан да ким була алмый.

6. Җирлек Советы һәм Җирлек башлыгы тарафыннан бергә чыгарылган референдум уздыру инициативасы Җирлек Советы карары һәм Җирлек башлыгы карары белән рәсмиләштерелә.

7. Җирлек Советы җирле референдумны җирле референдум үткәрү инициативасы турындагы документлар Җирлек Советына кергән көннән соң 30 көн эчендә билгели.

Җирле референдум Җирлек Советы тарафыннан тиешле срокларда билгеләнмәгән очракта, референдум гражданнарның, сайлау берләшмәләренең, Җирлек башлыгының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы Сайлау комиссиясенең яисә прокурорның мөрәҗәгате нигезендә суд тарафыннан билгеләнә. Суд тарафыннан билгеләнгән җирле референдум Җирлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан оештырыла, ә аны уздыруны тәэмин итү Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы яисә җирле референдумны үткәрүне тәэмин итү суд тарафыннан йөкләнгән башка орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8. Тавыш бирү йомгаклары һәм җирле референдумда кабул ителгән карар рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

9. Җирле референдумда кабул ителгән карар Җирлек территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм нинди дә булса дәүләт хакимияте органнары, аларның вазыйфаи затлары яисә җирле үзидарә органнары тарафыннан раслануга мохтаҗ түгел.

10. Җирле үзидарә органнары җирле референдумда кабул ителгән карарның үтәлешен әлеге Устав белән билгеләнгән вәкаләтләр бүлешү нигезендә тәэмин итәләр.

11. Җирле референдумны уздыру турындагы карарга, шулай ук җирле референдумда кабул ителгән карарга карата дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гражданнар, җирле үзидарә органнары, прокурор, федераль закон белән вәкаләт бирелгән прокурор тарафыннан  суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

**13 статья. Муниципаль сайлаулар**

1. Җирлектә муниципаль сайлаулар, гомуми тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш биреп, Җирлек Советы депутатларын сайлау максатыннан уздырыла.

2. Җирлек Советы депутаты итеп тавыш бирү көненә 18 яшькә җиткән һәм сайлау хокукына ия Россия Федерациясе гражданы сайланырга мөмкин.

3. Муниципаль сайлаулар Җирлек Советы тарафыннан билгеләнә. Муниципаль сайлауларны билгеләү турындагы карар тавыш бирү көненә кадәр 90 көннән дә иртәрәк һәм 80 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш. Әлеге карар кабул ителгән көненнән соң 5 көннән дә соңга калмыйча массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыгарга тиеш.

Сайлаулар вакытыннан алда  билгеләнгәндә, әлеге статьяда күрсәтелгән сроклар кыскартылырга мөмкин, әмма кимендә өчтән беренә генә.

Федераль законнарда, Татарстан Республикасы Сайлау кодексында билгеләнгән очракларда, муниципаль сайлаулар Җирлек сайлау комиссиясе яисә суд тарафыннан билгеләнә.

4. Муниципаль сайлауларны әзерләү һәм уздыру үз компетенцияләре чикләрендә Сайлау комиссиясенә йөкләнә.

5. Җирлек Советы депутатларын сайлаулар "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законда, Татарстан Республикасы Сайлау кодексында билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

6. Җирлек Советы депутатлары сайлау округына сайлаучылар вәкиллегенең уртача нормасы нигезендә төзелә торган бермандатлы сайлау округлары буенча сайлана.

7. Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның иң күп тавышын җыйган теркәлгән кандидат бермандатлы сайлау округы буенча сайланган дип танылa.

Әгәр Җирлек Советы депутатларын сайлауларда бермандатлы сайлау округында тавыш бирү бер кандидатура буенча үткәрелсә, тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар тавышларының кимендә 50 процентын җыйган кандидат сайланган дип санала. Теркәлгән кандидатлар тавышларны бертигез җыйса, алданрак теркәлгән кандидат сайланган дип санала.

8. Җирлек Советы депутатларын сайлауларның нәтиҗәләре рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

**14 статья. Җирлек Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү**

1. Җирлек Советы депутаты, шул исәптән Җирлек башлыгы, законда һәм әлеге Уставта билгеләнгән нигезләрдә һәм тәртиптә сайлаучылар тарафыннан чакыртып алынырга мөмкин.

2. Җирлек Советы депутатын чакыртып алуның нигезләре булып депутатның сайлаучыларның аңа карата ышанычын шик астына куя торган суд тәртибендә расланган конкрет хокукка каршы карарлары яки гамәлләре (гамәл кылмавы) һәм депутат бурычларын яисә Җирлек Башлыгы вазыйфаларын башкармау, депутат, Җирлек башлыгы статусына туры килми торган гамәлләр кылу һәм Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын, әлеге Уставны һәм башка муниципаль норматив хокукый актларны бозу тора.

3. Җирлек Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү халык инициативасы буенча уздырыла.

4. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтү һәм аны хуплап гражданнар имзаларын җыю өчен муниципаль сайлауларда катнашу хокукына ия кимендә 10 кешедән торган инициатив төркем төзелә.

5. Инициатив төркем инициатив төркемне теркәү турында үтенечнамә белән Җирлекнең сайлау комиссиясенә мөрәҗәгать итә. Инициатив төркем үтенечнамәсендә депутатны чакыртып алу өчен нигез булып торучы конкрет хокукка каршы карары яисә гамәле (гамәл кылмавы) күрсәтелергә тиеш, инициатив төркемнең һәр әгъзасының һәм Җирлек территориясендә аның исеменнән эш итәргә вәкаләтле затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, паспортының яисә граждан паспортын алыштыра торган документының сериясе, номеры һәм аны бирү датасы, шулай ук инициатив төркемнең һәр әгъзасының һәм аның исеменнән эш итәргә вәкаләтле затларның яшәү урыны адресы күрсәтелергә тиеш. Инициатив төркемнең үтенечнамәсенә күрсәтелгән төркемнең барлык әгъзалары имза салырга тиеш. Үтенечнамәдә күрсәтелгән хокукка каршы карарлар яисә гамәлләр (гамәл кылмау) расланган суд карары кушып бирелергә тиеш.

6. Инициатив төркемне теркәү, имзалар җыю, Җирлек Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү инициативасын хуплау йөзеннән, җыелган имзаларны тикшерү җирле референдум уздыру турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

7. Җирлек Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү Җирлек Советы тарафыннан билгеләнә һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, җирле референдум уздыру турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

8. Җирлек Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләүне Сайлау комиссиясе тарафыннан инициатив төркем үтенечнамәсен караганда, тиешле депутат аны чакыртып алу өчен нигез буларак күрсәтелә торган хәлләр турында аңлатмалар бирергә, кирәкле документларны тапшырырга хокуклы. Әлеге депутатка Җирлек Советы, Сайлау комиссиясе утырышлары уздыру көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча утырышларның уздырылу вакыты һәм урыны турында язма рәвештә алдан хәбәр ителергә тиеш.

9. Җирлек Советы депутаты, чакыртып алу буенча тавыш бирү уздырганда, чакыртып алу өчен нигез булган хәлләр турында сайлаучыларга аңлатмалар бирү максатыннан, инициатив төркем белән бертигез нигезләрдә агитация алып бару хокукына ия.

10. Җирлек Советы депутаты, шул исәптән Җирлек башлыгы, чакыртып алу өчен тиешле сайлау округында теркәлгән сайлаучыларның кимендә яртысы тавыш бирсә, чакыртып алынган дип санала.

11. Җирлек Совет депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

12. Сайлау комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгакларын рәсми чыгарганнан соң 5 көн эчендә инициатив төркемгә, Җирлек Советына һәм аны чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турында Җирлекнең әлеге депутатына язма рәвештә хәбәр итә.

**15 статья. Җирлек чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү**

1. Җирлек чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү халыкның әлеге үзгәрешкә ризалыгын алу максатларында уздырыла.

2. Җирлекнең барлык территориясендә яисә аның бер өлешендә Җирлек чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда уздырыла.

3. Җирлек  чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү Җирлек Советы тарафыннан билгеләнә һәм "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законда һәм "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып үткәрелә.

4. Җирлек чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү, әгәр сайлау хокукына ия Җирлектә яисә бер өлешендә яшәүчеләрнең яртысыннан күбрәге катнашса, уздырылган дип санала. Җирлекне үзгәртеп кору, күрсәтелгән үзгәрешләр өчен Җирлектә  яисә бер өлешендә яшәүчеләрнең яртысыннан күбрәге тавыш биргән булса, Җирлек чикләрен үзгәртүгә халыкның ризалыгы алынган дип санала.

5. Җирлек чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү йомгаклары һәм кабул ителгән карарлар рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

**16 статья. Гражданнарның хокукый инициативасы**

1. Гражданнар әлеге Устав һәм Җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә хокукый инициативага хокуклы.

2. Хокукый инициатива белән сайлау хокукына ия  Җирлек халкының кимендә 2 процентын тәшкил иткән гражданнар төркеме  чыгарга  мөмкин.

3. Хокукый инициативаны гамәлгә ашыру максатларында гражданнар түбәндәгеләргә хокуклы:

- гражданнарның хокукый инициатива күрсәтү һәм фикер алышу буенча яшәү урыны (эшләү) буенча җыелышларын һәм башка күмәк чараларны оештырырга һәм уздырырга;

- хокукый инициатива белән чыгуны хуплап имзалар җыю буенча инициатив төркемнәр төзергә;

- Җирлектә яшәүчеләрнең имзаларын җыярга һәм хокукый инициативаны законнарга каршы килмәгән ысуллар белән күрсәтүне хуплауга агитация алып барырга.

4. Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары гражданнарга хокукый инициативаны гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтергә тиеш.

5. Гражданнарның хокукый инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль норматив хокукый акт проекты аны керткән көннән алып өч ай эчендә Җирлек Советының ачык утырышында әлеге Уставта билгеләгән компетенцияләр нигезендә Җирлек Советы яисә Җирлек башлыгы тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш.

6. Гражданнарның хокукый инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль хокукый акт проектын караганда, гражданнарның инициатив төркеме вәкилләренә үз позицияләрен бәян итү мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш.

7. Гражданнарның хокукый инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль норматив хокукый акт проектын карау процедурасы Җирлек Советы регламенты, Җирлек башлыгының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

8. Гражданнарның хокукый инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль хокукый акт проектын карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән нигезле карар рәсми рәвештә язмача гражданнарның инициатив төркеменә җиткерелергә тиеш.

### 17 статья. Инициатив проектлар

1. Муниципаль берәмлектә яисә аның өлешендә яшәүчеләр өчен өстенлекле әһәмияткә ия чараларны гамәлгә ашыру максатларында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне яисә җирле үзидарә органнарына бирелгән башка мәсьәләләрне хәл итү хокукы бирелгән җирле администрациягә инициатив проект кертелергә мөмкин. Инициатив проектлар гамәлгә ашырыла ала торган муниципаль берәмлек территориясе өлешен билгеләү тәртибе муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

2. Инициатив проектны кертү инициативасы белән уналты яшькә җиткән һәм әлеге муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче кимендә ун гражданнан торган инициатив төркем, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, авыл торак пункты старостасы (алга таба - проект инициаторлары) чыгарга хокуклы. Инициатив төркемнең минималь саны муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән киметелергә мөмкин. Проект инициаторы булу хокукы муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый акты нигезендә шулай ук тиешле муниципаль берәмлек территориясендә эшчәнлек алып баручы башка затларга да бирелергә мөмкин.

3. Инициатив проектта түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

1) муниципаль берәмлек халкы яисә аның өлеше өчен өстенлекле әһәмияткә ия проблеманы тасвирлау;

2) күрсәтелгән проблеманы хәл итү буенча тәкъдимнәрне нигезләү;

3) инициатив проектны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәсен (көтелгән нәтиҗәләрен) тасвирлау;

4) инициатив проектны гамәлгә ашыруга кирәкле чыгымнарны алдан исәпләү

5) инициатив проектны гамәлгә ашыруның планлаштырыла торган сроклары;

6) әлеге проектны гамәлгә ашыруда кызыксынучы затларның планлаштырыла торган (мөмкин булган) финанс, мөлкәт һәм (яисә) хезмәти катнашуы турында белешмәләр;

7) инициатив проекны гамәлгә ашыру күздә тотылганда, җирле бюджет акчалары күләмен күрсәтү, планлаштырылган инициатив түләүләр күләменнән тыш;

8) муниципаль берәмлек территориясенә яисә аның чикләрендә муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый актында билгеләнгән тәртип нигезендә инициатив проект гамәлгә ашырылачак өлешен күрсәтү;

9) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый актында каралган башка белешмәләр.

4. Инициатив проект аны җирле администрациягә керткәнче гражданнар җыенында, җыелышында яисә конференциясендә, шул исәптән территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында яисә конференциясендә, инициатив проект турында фикер алышу, аның муниципаль берәмлек яисә аның өлеше халкы мәнфәгатьләренә туры килүен билгеләү, инициатив проектны гамәлгә ашыруның максатка ярашлылыгын билгеләү, шулай ук инициатив проектны хуплау турында гражданнарның җыены, җыелышы яисә конференциясендә каралырга тиеш. Шул ук вакытта бер җыенда, бер җыелышта яки гражданнарның бер конференциясендә берничә инициатив проект каралырга мөмкин.

Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән шулай ук гражданнарны сораштыру, имзалар җыю юлы белән инициатив проектка ярдәм итү мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерен ачыклау мөмкинлеге каралырга мөмкин.

Инициатив проектны җирле администрациягә керткәндә, проектның инициаторлары аңа гражданнар җыены, җыелышы яисә конференциясе беркетмәсен, гражданнарны сораштыру нәтиҗәләрен һәм (яисә) муниципаль берәмлек халкының инициатив проектка ярдәм итүен раслый торган имзалар кәгазьләрен теркиләр.

5. Инициатив проектны җирле администрациягә кертү турындагы мәгълүмат инициатив проект җирле администрациягә кертелгән көннән алып өч эш көне эчендә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) һәм муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылырга тиеш һәм әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне, шулай ук проект инициаторлары турында белешмәләрне үз эченә алырга тиеш. Бер үк вакытта гражданнар җирле администрациягә үзләренең тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен, аларны тәкъдим итү срогын күрсәтеп, биш эш көненнән дә ким була алмаган срокта тәкъдим итү мөмкинлеге турында хәбәр итә. Үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен уналты яшькә җиткән муниципаль берәмлек халкы җибәрергә хокуклы. Җирлекнең җирле администрациясенең әлеге мәгълүматны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру мөмкинлеге булмаган очракта, күрсәтелгән мәгълүмат составына әлеге Җирлек кергән муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырыла. Әлеге мәгълүмат

авыл торак пункты гражданнарына авыл торак пункты старостасы тарафыннан җиткерелергә мөмкин.

6. Инициатив проект кертелгән көненнән соң 30 көн эчендә җирле администрация тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш. Инициатив проектны карау нәтиҗәләре буенча җирле администрация түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) инициатив проектны хупларга һәм җирле бюджет турындагы карарда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә җирле бюджет проектын төзү һәм карау (җирле бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү) тәртибе нигезендә тиешле максатларга һәм (яки) җирле бюджет турындагы карарда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә эшне дәвам итәргә;

2) инициатив проектны хуплаудан баш тартырга һәм инициатив проектны хуплаудан баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, аны проект инициаторларына кире кайтарырга.

7. Җирле администрация түбәндәге очракларның берсендә инициатив проектны хуплаудан баш тарту турында карар кабул итә:

1) инициатив проектны кертүнең һәм аны карауның билгеләнгән тәртибен үтәмәү;

2) инициатив проектның Россия Федерациясенең федераль законнары һәм башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары таләпләренә, муниципаль берәмлек уставына туры килмәве;

3) җирле үзидарә органнарының кирәкле вәкаләтләре һәм хокуклары булмаганлыктан, инициатив проектны гамәлгә ашыру мөмкинлеге булмау;

4) инициатив проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар күләмендә түләү чыганагы булып инициатив түләүләр торган җирле бюджет акчалары булмау;

5) инициатив проектта тасвирланган проблеманы нәтиҗәлерәк хәл итү мөмкинлеге булу;

6) инициатив проектны конкурс сайлавын узмаган дип тану.

8. Җирле администрация, әлеге статьяның 7 өлешендәге 5 пунктында каралган очракта, проект инициаторларына инициатив проектны бергәләп эшләп бетерергә, шулай ук аны башка муниципаль берәмлекнең яисә аларның компетенциясе нигезендә дәүләт органының җирле үзидарә органына тәкъдим итәргә тиеш.

9. Инициатив проектларны күрсәтү, кертү, тикшерү, карау, шулай ук аларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибе муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы (вәкиллекле орган вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы гражданнар җыены) тарафыннан билгеләнә.

10. Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан бюджетара трансфертлар исәбеннән финанс ярдәме алу өчен чыгарыла торган инициатив проектларга карата, инициатив проектларда булырга тиешле белешмәләр составына карата таләпләр, инициатив проектларны карау тәртибе, шул исәптән аларны хуплаудан баш тарту өчен нигезләр, мондый инициатив проектларны конкурс нигезендә сайлап алу тәртибе һәм критерийлары закон һәм (яисә) Россия Федерациясе субъектының башка норматив хокукый акты нигезендә билгеләнә. Бу очракта әлеге статьяның 3, 6, 7, 8, 9, 11 һәм 12 өлешләрендәге таләпләр кулланылмый.

11. Әгәр җирле администрациягә шул исәптән эчтәлеге буенча шундый ук өстенлекле проблемаларны тасвирлап берничә инициатив проект кертелгән булса, җирле администрация конкурс нигезендә сайлап алу оештыра һәм бу хакта проект инициаторларына хәбәр итә.

12. Инициатив проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү коллегиаль органга (комиссиягә) йөкләнә, аны төзү һәм аларның эшчәнлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә. Коллегиаль органның (комиссиянең) составы җирле администрация тарафыннан төзелә. Шул исәптән, коллегиаль орган (комиссия) әгъзаларының гомуми санының яртысы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тәкъдимнәре нигезендә билгеләнергә тиеш. Конкурс нигезендә сайлап алу уздырганда, проект инициаторларына һәм аларның вәкилләренә коллегиаль орган (комиссия) тарафыннан инициатив проектларны карауда катнашу һәм алар буенча үз позицияләрен бәян итү мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш.

13.Проект инициаторлары, әлеге муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче башка гражданнар, гражданнар җыены, җыелышы яки конференциясе белән вәкаләтле затлар, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган башка затлар, Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган рәвешләрдә инициативалы проектны гамәлгә ашыруны иҗтимагый контрольдә тотарга хокуклы.

14. Җирле администрациянең инициатив проектын карау турында, инициатив проектны гамәлгә ашыру барышы турында, шул исәптән акчаларны куллану турында, аны гамәлгә ашыруда кызыксынучы затларның мөлкәти һәм (яисә) хезмәт катнашуы турында мәгълүмат "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм урнаштырылырга тиеш. Инициатив проектны гамәлгә ашыру йомгаклары турында җирле администрация хисабы инициатив проектны гамәлгә ашыру тәмамланган көннән алып 30 календарь көн эчендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм урнаштырылырга тиеш. Җирлекнең җирле администрациясенең мәгълүматны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру мөмкинлеге булмаган очракта, әлеге мәгълүмат составына әлеге җирлек кергән муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырыла. Әлеге мәгълүмат авыл торак пунктында гражданнарга авыл торак пункты старостасы тарафыннан җиткерелергә мөмкин.

## 18 статья. Территориаль иҗтимагый үзидарә

1. Җирлектә территориаль иҗтимагый үзидарә гражданнарның җыелышларын һәм конференцияләрен үткәрү юлы белән, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын төзү юлы белән турыдан-туры халык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Территориаль иҗтимагый үзидарә гражданнарның түбәндәге яшәү территорияләре чикләрендә гамәлгә ашырыла: күпфатирлы торак йорт подъезды; күпфатирлы торак йорт; торак йортлар төркеме; торак микрорайон; Җирлек булмаган авыл торак пункты; гражданнар яшәгән башка территорияләр.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган территория чикләре тиешле территориядә яшәүче халыкның тәкъдиме буенча Җирлек Советында раслана торган җирлектә территориаль иҗтимагый үзидарә турындагы Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә билгеләнә.

4. Территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган территория шундый ук башка территория составына керә алмый.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарә аның Уставы нигезендә юридик зат була ала һәм коммерциячел булмаган оешманың оештыру-хокукый формасында дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

6. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставында түбәндәгеләр билгеләнә:

1) ул гамәлгә ашырыла торган территория;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең максатлары, бурычлары, формалары һәм төп юнәлешләре;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының вәкаләтләрен формалаштыру, туктату, вәкаләтләре чоры;

4) карарлар кабул итү тәртибе;

5) мөлкәт сатып алу тәртибе, шулай ук күрсәтелгән мөлкәттән һәм финанс чараларыннан файдалану һәм алар белән эш итү тәртибе;

6) территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыруны туктату тәртибе.

7. Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеге мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышлары, конференцияләре аның Уставы нигезендә чакырыла.

8. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышы, әгәр анда уналтынчы яшькә җиткән территория халкының өчтән береннән дә ким булмаган өлеше катнашса, вәкаләтле дип санала.

Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар конференциясе, гражданнар җыелышларында уналтынчы яшькә җиткән, Тиешле территориядә яшәүчеләрнең өчтән береннән дә ким булмаган өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

9. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыручы гражданнар җыелышының, конференциясенең махсус вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары структурасын билгеләү;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын кабул итү, аңа үзгәрешләр кертү;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын сайлау;

4) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү;

5) территориаль иҗтимагый үзидарә керемнәре һәм чыгымнары сметасын һәм аның үтәлеше турындагы хисапны раслау;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы хисапларны карау һәм раслау;

7) инициатив проект турында фикер алышу һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.

10. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары:

1) тиешле территориядә яшәүче халыкның мәнфәгатьләрен тәкъдим итәләр;

2) гражданнар җыелышларында һәм конференцияләрендә кабул ителгән карарларның үтәлешен тәэмин итәләр;

3) территорияне карап тоту, төзекләндерү буенча хуҗалык эшчәнлеген, тиешле территориядә яшәүче гражданнарның социаль-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән башка хуҗалык эшчәнлеген, күрсәтелгән гражданнар акчалары исәбеннән дә, шулай ук Җирлекнең башкарма комитеты белән килешү нигезендә Җирлек бюджеты акчаларын кулланып, Җирлек башкарма комитеты белән дә башкара алалар;

4) җирле үзидарә органнарына (Җирлек Советына, Җирлек башлыгына һәм Җирлек башкарма комитетына) әлеге органнар һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан мәҗбүри каралырга тиешле муниципаль норматив хокукый актлар проектларын кертергә хокуклы.

11. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары проект инициаторлары буларак инициатив проектны тәкъдим итә ала.

12. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе, җирле бюджеттан кирәкле акчаларны бүлеп бирү шартлары һәм тәртибе әлеге Устав һәм Җирлек Советның норматив хокукый акты белән билгеләнә.

## 19 статья. Авыл торак пункты старостасы

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне авыл торак пунктында хәл иткәндә, җирле үзидарә органнарының һәм авыл торак пунктында яшәүчеләрнең үзара хезмәттәшлеген оештыру өчен Җирлектә урнашкан авыл торак пункты старостасы билгеләнергә мөмкин.

2. Авыл торак пункты старостасы әлеге авыл торак пункты территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия затлар арасыннан авыл торак пункты гражданнары җыенын тәкъдим итү буенча аның составына әлеге авыл торак пункты кергән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнә.

3. Авыл торак пункты старостасы дәүләт вазыйфасын, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын, муниципаль вазыйфаны яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче зат булмый, җирле үзидарә органнары белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә һәм алар белән турыдан-туры бәйле башка мөнәсәбәтләрдә була алмый.

4. Авыл торак пункты старостасы итеп ттүбәндәге затлар билгеләнә алмый:

1) дәүләт вазыйфасын, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын, муниципаль вазыйфа яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче;

2) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган;

3) юкка чыгарылмаган яисә алынмаган хөкем ителүе булган.

5. Авыл торак пункты старостасы вәкаләтләре срогы биш ел.

Авыл торак пункты старостасы вәкаләтләре составына әлеге авыл торак пункты кергән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40

статьясындагы 10 өлешенең 1-7 пунктларында билгеләнгән очракларда, авыл торак пункты гражданнары җыены тәкъдиме буенча вакытыннан алда туктатыла.

6. Авыл торак пункты старостасы үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен:

1) авыл торак пунктында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр һәм башка оешмалар белән хезмәттәшлек итә;

2) халык белән, шул исәптән гражданнар җыеннарында, җыелышларында, конференцияләрендә катнашу юлы белән хезмәттәшлек итә, мондый чаралар нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан мәҗбүри каралырга тиешле муниципаль хокукый актлар проектлары рәвешендә рәсмиләштерелгән мөрәҗәгатьләрне һәм тәкъдимнәрне, шул исәптән рәсмиләштерелгән мөрәҗәгатьләр һәм тәкъдимнәр җибәрә;

3) җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча авыл торак пункты халкына мәгълүмат бирә, шулай ук аларны җирле үзидарә органнарыннан алынган башка мәгълүматка җиткерүдә ярдәм итә;

4) җирле үзидарә органнарына гавами тыңлаулар һәм иҗтимагый фикер алышулар оештыруда һәм уздыруда, аларның нәтиҗәләрен авыл торак пунктында халыкка игълан итүдә ярдәм итә;

5) авыл торак пунктында яшәүчеләр өчен өстенлекле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча инициатив проект кертү инициативасы белән чыгыш ясарга хокуклы;

6) муниципаль берәмлек уставында һәм (яисә) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый актында Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә каралган башка вәкаләтләрне һәм хокукларны гамәлгә ашыра.

7. Авыл торак пунктының старостасы эшчәнлек гарантияләре һәм статусының башка мәсьәләләре муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә билгеләнә ала.

### 20 статья. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибе

1. Гражданнар, җирле үзидарә органнары инициативасы буенча Җирлек чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарә булдыру максатларында әлеге территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территориядә яшәүче гражданнарның җыелышларын әзерләүне гамәлгә ашыручы гражданнарның инициатив төркеме төзелә.

2. Гражданнар җыелышы тиешле территориядә территориаль иҗтимагый үзидарә төзү турында карар, аның уставын кабул итә, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәүгә бәйле мәсьәләләр буенча Җирлек Советында гражданнар җыелышы исеменнән эш итәргә вәкаләтле вәкилне (вәкилләрне) билгели.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә Уставы Җирлек Советы тарафыннан теркәлгәннән соң гамәлгә куелган дип санала.

### 21 статья. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү тәртибе

1. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү өчен гражданнар җыелышының вәкаләтле вәкиле (вәкилләре) Җирлек башлыгына түбәндәгеләрне тапшырыла:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү турында гражданнар җыелышының барлык вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган гариза;

2) гражданнарның фамилиясен, исемен, атасының исемен, туу датасын, паспортының яисә паспортын алмаштыручы документының сериясен, номерын һәм бирелү датасын, вәкаләтле вәкилләрнең һәркайсының яшәү урыны адресын күрсәтеп, территориаль иҗтимагый үзидарә төзү турында карар кабул ителгән гражданнар җыелышы беркетмәсе;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә уставының ике нөсхәсе.

2. Әлеге статьяның 1 пунктында билгеләнгән документлардан тыш, башка документларны тапшыруны таләп итү рөхсәт ителми.

Вәкаләтле вәкилгә, исемлекне һәм аларны алу датасын күрсәтеп, документларны кабул итү турында расписка бирелә.

3. Җирлек башлыгы территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү турындагы документлар кергән көннән соң ике атна эчендә уставны теркәү яки аны теркәүдән баш тарту турында карар проектын алдан карау һәм әзерләүне оештыра.

4. Гражданнар җыелышының вәкаләтле вәкилләре территориаль иҗтимагый үзидарә уставын алдан караганда Җирлек Советы утырышында тавыш бирү хокукы белән катнашырга хокуклы.

5. Җирлек Советының территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү яисә аны теркәүдән баш тарту турында карары Җирлек башлыгы тарафыннан әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән документлар кабул итеп алынганнан соң 30 көн эчендә кабул ителә. Уставны теркәүдән баш тарту дәлилләнгән булырга тиеш.

6. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәүдән баш тарту өчен нигез булып территориаль иҗтимагый үзидарә уставының Россия Федерациясе Конституциясе нормаларына, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы законнарына, Җирлек Уставына, башка муниципаль норматив хокукый актларга каршы килүе тора.

7. Территориаль иҗтимагый үзидарә төзүнең максатка ярашсызлыгы сәбәбе буенча территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәүдән баш тарту рөхсәт ителми.

8. Җирлек Советы тарафыннан кабул ителгән территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү мәсьәләсе буенча дәлилләнгән карар өч көн эчендә рәсми рәвештә гражданнар җыелышының вәкаләтле вәкиле (вәкаләтле вәкилләре) игътибарына язма рәвештә җиткерелергә тиеш.

9. Җирлек Советы территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү турында карар кабул иткән очракта, уставның бер нөсхәсе, теркәлү турында тамга куелып, гражданнар җыенының вәкаләтле вәкиленә тапшырыла, икенче нөсхәсе Җирлек Советында саклана.

10. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставына кертелә торган үзгәрешләр Җирлек Советы тарафыннан әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә теркәлергә тиеш. Әлеге үзгәрешләр аларны теркәгән көннән үз көченә керә.

**22 статья. Гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар**

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль норматив хокукый актлар проектларын тикшерү өчен Җирлек Советы, Җирлек башлыгы тарафыннан Җирлек халкы катнашында гавами тыңлаулар үткәрелергә мөмкин.

2. Гавами тыңлаулар халык, Җирлек Советы яки Җирлек башлыгы, Башкарма комитет җитәкчесе инициативасы белән үткәрелә. Халык яки Җирлек Советы инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар Җирлек Советы тарафыннан, ә Җирлек башлыгы, Башкарма комитет җитәкчесе инициативасы буенча үткәрелә торганнары Җирлек башлыгы тарафыннан билгеләнә.

3. Гавами тыңлауларда түбәндәгеләр чыгарылырга тиеш:

1) Җирлек уставы проекты, шулай ук әлеге уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, муниципаль берәмлек уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яки Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләрен әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертелү очракларыннан тыш;

2) Җирлек бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) Җирлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проекты;

4) җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору өчен тавыш бирү юлы белән яисә гражданнар җыеннарында муниципаль берәмлек халкының ризалыгын алу таләп ителү очракларыннан тыш.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү турындагы карар, әгәр гамәлдәге законнарда башкача каралмаган булса, тиешле орган яисә җирлекнең вазыйфаи заты тарафыннан муниципаль норматив хокукый акт проекты караласы көнгә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

5. Аларны үткәрү вакытын һәм урынын күрсәтеп, гавами тыңлаулар уздыру турындагы карар һәм гавами тыңлауларга чыгарыла торган тиешле муниципаль норматив хокукый акт проекты гавами тыңлаулар уздырыласы көнгә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш, әгәр гамәлдәге законнарда башкасы каралмаган булса.

6. Гавами тыңлаулар үткәрү турында карар басылып чыккан көннән алып һәм аларны уздыру көненә кадәр Җирлек халкы Җирлек башлыгына гавами тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шул исәптән муниципаль норматив хокукый акт проектына төзәтмәләр һәм башка тәкъдимнәр җибәрергә хокуклы. Җирлек башлыгы кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерүне оештыра. Әлеге тәкъдимнәр һәм искәрмәләр гавами тыңлауларда катнашучыларга җиткерелә.

7. Әгәр гамәлдәге законнарда башкасы каралмаган булса, гавами тыңлаулар муниципаль норматив хокукый акт проекты караласы көнгә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча уздырыла. Гавами тыңлаулар белгечләрне, экспертларны, кызыксынган затларны чакыру юлы белән үткәрелә. Гавами тыңлауларда Җирлекнең теләсә кайсы кешесе катнашырга хокуклы.

8. Гавами тыңлаулар уздыру йомгаклары буенча муниципаль норматив хокукый акт проектын кабул итү алар компетенциясенә кергән Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан мәҗбүри каралырга тиешле тәкъдимнәр кабул ителә.

9. Гавами тыңлауларның нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләмәсен дә кертеп, гавами тыңлаулар уздырганнан соң 5 көннән дә соңга калмыйча басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

10. Гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе Җирлек Советы карары белән расланган гавами тыңлаулар турында Нигезләмә белән билгеләнә.

11. Әлеге статьяда күрсәтелгән сроклар, гамәлдәге законнар белән гавами тыңлаулар өчен каралган башка сроклар билгеләнмәгән булса кулланыла.

12. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияләрне межалау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның чик параметрларыннан читкә китүгә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары буенча, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның башка төренә рөхсәт ителгән бер төрен үзгәртү мәсьәләләре буенча, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең расланмаган очракта, җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар үткәрелә, аларны оештыру һәм үткәрү тәртибе шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон нигезләмәләрен исәпкә алып, Җирлек Советы карары белән билгеләнә.

**23 статья. Гражданнар җыелышы**

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр турында фикер алышу, Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары эшчәнлеге турында халыкка мәгълүмат бирү, Җирлек территориясе өлешендә территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру өчен гражданнар җыелышлары үткәрелергә мөмкин. Гражданнар җыелышы микрорайоннар, торак массивлар, кварталлар, урамнар, торак йортлар буенча чакырыла.

2. Гражданнар җыелышы халык инициативасы, Җирлек Советы, Җирлек башлыгы инициативасы буенча, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә уставында каралган очракларда үткәрелә.

3. Җирлек Советы яисә Җирлек башлыгы инициативасы белән уздырыла торган гражданнар җыелышы Җирлек Советы яисә Җирлек Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

4. Халык инициативасы белән үткәрелә торган гражданнар җыелышы территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының язма тәкъдиме буенча Җирлек Советы, әлеге территориядә яшәүче һәм әлеге территорияләрдә урнашкан предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләре, җыелышта катнашырга хокуклы кимендә 10 процент тәшкил иткән гражданнар төркемнәре тарафыннан билгеләнә.

Гражданнар җыелышын үткәрү турындагы тәкъдимдә карауга чыгарыла торган мәсьәләләр исемлеге, җыелышны уздыру вакыты һәм урыны күрсәтелергә тиеш. Тәкъдим вәкаләтле затлар тарафыннан имзаланырга тиеш, әгәр җыелышны үткәрү инициативасы белән гражданнар төркеме мөрәҗәгать итсә - әлеге гражданнарның һәркайсының фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган көнен, яшәү урыны адресын күрсәтеп.

Җирлек Советы үзенең алдагы утырышында гражданнар җыелышын үткәрү турында кертелгән тәкъдимне карый.

Җирлек Советы аның максатка ярашсызлыгы сәбәбе буенча гражданнар җыелышын үткәрүдән баш тартырга хокуклы түгел.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру максатларында гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән билгеләнә.

Инициатив проектлар кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында уналты яшькә җиткән тиешле территориядә яшәүчеләр катнашырга хокуклы. Инициатив проектларны кертү мәсьәләләрен карау һәм тикшерү максатларында гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

6.Гражданнар җыелышын үткәрү вакыты һәм урыны турында һәм фикер алышуга кертелә торган мәсьәләләр турында әлеге территориядә яшәүчеләргә җыелыш уздырыласы көнгә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча массакүләм мәгълүмат чаралары, почта аша  хәбәр итеп һәр фатирлар буенча йөреп, белдерүләр һәм башка мөмкин булган чаралар кулланып хәбәр ителә.

Гражданнар җыелышын әзерләүне һәм уздыруны Җирлекнең Башкарма комитеты тәэмин итә.

7. Җыелышлар эшендә әлеге территориядә яшәүче, сайлау хокукына ия гражданнар катнашырга хокуклы. Җыелышта катнашырга хокукы булган гражданнарның гомуми саны муниципаль сайлаулар уздырганда файдаланыла торган Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәүне исәпкә алу күрсәткечләре нигезендә билгеләнә.

Җыелышта катнашырга хокукы булган гражданнар санының кимендә өчтән бере катнашса, гражданнар җыелышы хокуклы дип санала.

Җыелыш карарлары җыелышта катнашкан гражданнарның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

8. Гражданнар җыелышы җирле үзидарә органнарына һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларына мөрәҗәгать кабул итәргә, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары белән үзара мөнәсәбәтләрдә гражданнар җыелышы исеменнән эш итәргә вәкаләтле затларны сайларга мөмкин.

9. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча үткәрелә торган гражданнар җыелышы үз компетенциясенә территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән кертелгән мәсьәләләр буенча карар кабул итә.

10.Гражданнар җыелышы тарафыннан кабул ителгән мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгатьләрдә булган мәсьәләләрне хәл итү компетенцияләрендә булган җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан язмача җавап җибәрү белән мәҗбүри каралырга тиеш.

11. Гражданнар җыелышын билгеләү һәм уздыру тәртибе, шулай ук гражданнар җыелышының вәкаләтләре федераль закон, әлеге Устав һәм Җирлек Советының норматив хокукый акты, территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән билгеләнә.

12. Гражданнар җыелышы йомгаклары аны уздырганнан соң бер ай эчендә рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

## 24 статья. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы)

1. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча фикер алышу һәм Җирлектәге барлык халыкның фикерен ачыклау кирәк булган очракта уздырыла. Җирлекнең тиешле территориаль өлешләрендә яшәүчеләр арасыннан гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) гражданнар җыелышын чакыру кыен булганда, шул исәптән тиешле территориядә яшәүче һәм гражданнар җыелышында катнашырга хокукы булган кешеләр саны 100 кешедән артып киткән очракларда үткәрелә.

2. Гражданнар конференциясен (делегатлар җыелышын) билгеләү һәм үткәрү, делегатлар сайлау тәртибе әлеге Устав, Җирлек Советының норматив хокукый акты, территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән билгеләнә.

3. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) гражданнар җыелышы вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

4. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) халык, Җирлек Советы, Җирлек башлыгы инициативасы буенча уздырыла. Җирлек Советы яисә Җирлек башлыгы инициативасы белән уздырыла торган гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) Җирлек Советы яисә Җирлек башлыгы тарафыннан билгеләнә. Халык инициативасы белән уздырыла торган гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) Җирлек Советы тарафыннан билгеләнә.

5. Әгәр анда уналтынчы яшькә җиткән тиешле территориядә яшәүчеләрнең өчтән берен тәшкил иткән делегатларның гражданнар җыелышларында сайланган өчтән икесе катнашса, гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) хокуклы дип санала. Конференция карарлары (делегатлар җыелышлары) конференциядә катнашучы делегатларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

6. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) йомгаклары аны уздырганнан соң бер ай эчендә рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

## 25 статья. Гражданнар җыены

1. "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда гражданнар җыены түбәндәгечә үткәрелергә мөмкин:

1) күрсәтелгән торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль районы) территориясенә кертүне сорый торган торак пунктта әлеге торак пункт составына кергән Җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча;

2) Җирлек составына керүче торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

3) авыл торак пунктында авыл торак пункты старостасы кандидатурасын күрсәтү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

4) авыл торак пунктында гражданнар җыены, шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар күрсәтү максатларында үткәрелергә мөмкин.

5) гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган Җирлектә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре инициатив проектлар күрсәтү, әзерләү, сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча;

6) Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә Җирлек составына кергән торак пункт, шәһәр эчендәге район, федераль әһәмияттәге шәһәр эчендәге территория, муниципаль округ, шәһәр округы территорияләренең яисә муниципаль район чикләрендә авылара территориядә урнашкан торак пунктның әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

2. “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131 ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясындагы 1 өлешенең 4_3 пунктында каралган гражданнар җыены кимендә 10 кеше булган торак пункт территориясенең тиешле өлешендә яшәүче халык төркеме инициативасы буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан чакырылырга мөмкин.

Җирлек составына кергән торак пункт, шәһәр эчендәге район, федераль әһәмияттәге шәһәр эчендәге территория, муниципаль округ, шәһәр округы территориясе яисә анда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрелергә мөмкин булган муниципаль район чикләрендә урнашкан авылара территория өлеше чикләрен билгеләү критерийлары Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә.

3. Әлеге статьяда каралган гражданнар җыены торак пунктта яшәүчеләрнең (яисә аның территориясе өлешендә) яисә җирлектә яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы катнашканда хокуклы. Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия яртысыннан артыгын бер үк вакытта бергә җыю мөмкинлеге булмаган очракта, муниципаль берәмлек уставы нигезендә, гражданнар җыены Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә белән расланган тәртиптә, гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгән көннән бер айдан артмаган вакыт эчендә этаплап уздырыла. Шул ук вакытта, элегрәк гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә катнашуның алдагы этапларында катнашмый. Гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, халык җыены карары кабул ителгән дип санала.

**26 статья. Гражданнарны сораштыру**

1. Гражданнарны сораштыру  җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары карарлар кабул иткәндә халык фикерен ачыклау һәм исәпкә алу өчен җирлекнең бөтен территориясендә яисә территориясенең бер өлешендә үткәрелә.

Сораштыру нәтиҗәләре киңәш итү характерында.

2. Гражданнарны сораштыруда сайлау хокукына ия муниципаль берәмлек халкы катнашырга хокуклы. Гражданнарны тәкъдим ителгән инициатив проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча сораштыруда  уналты яшькә җиткән муниципаль берәмлек яисә аның өлеше халкы катнашырга хокуклы.

3. Гражданнарны сораштыру түбәндәгеләр инициативасы белән уздырыла:

1) Җирлек Советы яисә Җирлек башлыгы - җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары - җирлек җирләренең максатчан билгеләнешен үзгәртү турында карарлар кабул иткәндә гражданнарның фикерен исәпкә алу өчен.

3) инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган муниципаль берәмлектә  яисә аның өлешендә уналты яшькә җиткән яшәүчеләр   - әлеге инициатив проектка ярдәм итү турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен.

4. Гражданнарны сораштыру билгеләү һәм уздыру тәртибе Татарстан Республикасы законы нигезендә Җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

5. Гражданнарны сораштыру билгеләү турындагы карар муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан кабул ителә. Гражданнарны сораштыру үткәрү өчен "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайты кулланылырга мөмкин. Гражданнарны сораштыру билгеләү турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый актында түбәндәгеләр билгеләнә:

1) сораштыруны уздыру датасы һәм сроклары;

2) сораштыру уздырганда тәкъдим ителә торган (тәкъдим ителә торган) сорауны (сорауларны) әзерләү;

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру кәгазенең формасы;

5) сораштыруда катнашучы җирлек халкының иң аз саны.

6) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып гражданнардан сораштыру үткәрелгән очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.

6. Җирлектә яшәүчеләргә гражданнардан сораштыру үткәрү турында хәбәр аны үткәрүгә кимендә 10 көн кала белдерелә.

7. Гражданнарны сораштыру әзерләүгә һәм уздыруга бәйле чараларны финанслау түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1)Җирлек бюджеты акчалары исәбеннән-Җирлекнең җирле үзидарә органнары яки муниципаль берәмлек халкы инициативасы буенча сораштыру үткәргәндә;

2) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән - Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы буенча сораштыру уздырганда.

8. Сораштыру нәтиҗәләре аны уздырганнан соң бер ай эчендә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Җирлектә яшәүче теләсә кайсы кеше сораштыру нәтиҗәләре белән танышырга хокуклы. Җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешле карарлар кабул ителгәндә сораштыру нәтиҗәләре исәпкә алынырга тиеш.

**27 статья. Җирле әһәмияттәге аеруча мөһим мәсьәләләр буенча халык фикер алышуы**

1. Муниципаль хокукый актлар проектларын һәм җирле әһәмияттәге башка аеруча мөһим мәсьәләләрне халык фикер алышуына чыгару турындагы карар Җирлек Советы тарафыннан үз инициативасы буенча яисә әлеге территориядә

яшәүче гражданнар таләбе буенча Җирлек Советы билгеләгән тәртиптә кабул ителә.

2. Муниципаль хокукый акт проекты тексты һәм халык фикер алышуына чыгарыла торган мәсьәләләр буенча башка материаллар аларны халык фикер алышуына чыгару турында карар кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла, халыкка танышу өчен мөмкин булган урыннарда урнаштырыла, башка ысуллар белән халыкка җиткерелә.

3. Халык фикер алышуына мәсьәлә чыгару белән бер үк вакытта Җирлек Советы фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне карау эшен оештыру вакытын һәм тәртибен билгели, әлеге максат өчен махсус комиссия төзи.

4. Җирлек Советы үзе чыгара торган муниципаль хокукый актлар проектлары һәм җирле әһәмияттәге башка аеруча мөһим мәсьәләләр турында фикер алышуны тәэмин итә, моның өчен кирәкле шартлар тудыра.

5. Халык фикер алышуына чыгарылган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр Җирлек Советына җибәрелә.

6. Муниципаль хокукый актлар проектлары һәм җирле әһәмияттәге башка аеруча мөһим мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр Җирлек Советы тарафыннан карала.

7. Халык фикер алышуы йомгаклары турында халыкка хәбәр ителә.

**28 статья. Гражданнарның җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгатьләре**

1. Гражданнар җирлекнең җирле үзидарә органнарына шәхсән һәм күмәк мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда каралырга тиеш.

3. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен һәм срокларын бозган өчен җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплы.

**29 статья. Җирлек халкы тарафыннан җирле үзидарәне гамәлгә ашыру һәм аны гамәлгә ашыруда турыдан-туры катнашуның башка формалары**

1. Әлеге Уставта каралган җирле үзидарәне халык тарафыннан турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуы формалары белән беррәттән, гражданнар җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка рәвешләрдә катнашырга хокуклы.

2. Җирле үзидарәдә яшәүчеләрнең турыдан-туры катнашуы һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуы законлылык, иреклелек принципларына нигезләнә.

Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары халыкка җирле үзидарәдә яшәүчеләрнең турыдан-туры гамәлгә ашыруда һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуында ярдәм итәргә тиеш.

## III бүлек. Җирлек Советы

### 30 статья. Җирлек Советы - җирле үзидарәнең вәкиллекле органы

1. Җирлек Советы җирле үзидарәнең даими эшләүче сайланулы коллегиаль вәкиллекле органы булып тора.

2. Җирлек Советының рәсми исеме-Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Советы.

3. Җирлек Советының вәкаләтләре срогы  - 5 ел.

4.Җирлек Советы Җирлек халкына хисап тота һәм аның күзәтчелегендә.

5. Җирлек Советының мөһере, үз исеме булган бланклары бар.

6. Җирлек Советы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары җирлек бюджетында Россия Федерациясе бюджетларының чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

### 31 статья. Җирлек Советы составы

1. Җирлек Советы бермандатлы сайлау округлары буенча муниципаль сайлауларда сайланган 7  депутаттан тора.

2. Җирлек Советы аның составына Җирлек Советының билгеләнгән депутатлар санынннан кимендә өчтән икесен сайлаганда хокуклы була.

### 32 статья. Җирлек Советы депутаты статусы

1. Җирлек Советы депутаты вәкаләтләре аны сайлаган көннән башлана һәм яңа чакырылыш Җирлек Советы эшли башлаган көннән туктатыла.

2. Җирлек Советы депутаты, әлеге Уставта билгеләнгән очраклардан тыш, депутат эшчәнлеген төп эш урыны буенча эш һәм хезмәт бурычларын үтәгән килеш бергә алып бара.

Үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатына даими рәвештә эш урынын (вазыйфаларын) айга өч эш көне дәвамлылыгы белән саклау гарантияләнә.

3. Җирлек Советы депутаты статусына бәйле чикләүләр федераль законнар белән билгеләнә.

4. Җирлек Советы депутатына үз вәкаләтләрен тоткарлыксыз гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав, Җирлек Советы карарлары нигезендә  шартлар тәэмин ителә.

5. Җирлек Советы депутаты Җирлек Советы тарафыннан раслана торган депутат этикасы кагыйдәләрен үтәргә тиеш, аларда шул исәптән депутатның түбәндәге бурычлары булырга тиеш:

1) шәхсән яисә аның якын туганнарына кагылышлы мәсьәләләрне хәл иткәндә, җирле үзидарә органнары, оешмалар, вазыйфаи затлар, муниципаль хезмәткәрләр һәм гражданнар эшчәнлегенә йогынты ясау өчен депутат статусыннан файдаланмау;

2) депутат бурычларын объектив башкаруда шик тудырырлык үз-үзен тотышыннан тыелырга, шулай ук аның абруена яисә Җирлек Советы абруена зыян китерергә сәләтле низаглы хәлләрдән качарга;

3) мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү куркынычы булганда - шәхси кызыксыну депутат бурычларын объектив үтәүгә йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган вәзгыять туганда - бу хакта Җирлек Советына хәбәр итәргә һәм аның әлеге каршылыкны булдырмауга яисә җайга салуга юнәлдерелгән карарын үтәргә;

4) Җирлек Советында билгеләнгән гавами чыгышлар кагыйдәләрен үтәргә;

5) депутат эшчәнлегенә бәйле булмаган максатларда конфиденциаль характердагы белешмәләргә кертелгән, депутат вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә аңа мәгълүм булган белешмәләрне фаш итмәскә һәм файдаланмаска;

6) физик һәм юридик затлардан депутат бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләкләүләр (бүләкләр, акчалата бүләкләү, ссуда, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү һәм башка бүләкләүләр) алмаска.

6. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы Җирлек Советы депутаты түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) эшкуарлык эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләр советы идарәсендә, башка муниципаль берәмлекләр берләшмәләрендә, сәяси партиядә, профсоюз тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәлгән катнашудан тыш), башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференцияләрдә), Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез нигездә катнашудан тыш, муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итүне гамәлгә куючы яисә гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә, федераль законнарда каралган башка очракларда, гамәлгә куючысы (акционеры) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә органнарында һәм Ревизия комиссиясендә катнашырга;

2) мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлегеннән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый;

3) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаса, Россия Федерациясе территориясендә эш итүче коммерцияле булмаган хөкүмәткә карамаган чит ил оешмаларының һәм аларның структур бүлекчәләренең идарә органнары, попечительләр һәм күзәтүчеләр советлары, бүтән органнары составына керергә;

Даими нигездә вәкаләтләр башкаручы депутат гражданлык, административ яки җинаять эше буенча яки административ хокук бозу турындагы эш буенча яклаучы яки вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш) сыйфатында катнаша алмый.

Җирлек Советы депутатларының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге Устав белән билгеләнә.

7. Җирлек Советы депутаты "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны һәм бурычларны үтәргә тиеш.

8. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясының 7_2 өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, "Аерым категорияләрдәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларны саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында" 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) депутатка карата җирле үзидарә депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә бүтән җаваплылык чарасын куллану турында тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка гариза белән мөрәҗәгать итә.

9. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган мәгълүмат биргән җирле үзидарә депутатына карата, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында вазыйфа биләүдән мәхрүм итү белән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында вазыйфасыннан азат итү;

3) вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү белән аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) вәкаләтләре срогы тәмамланганчы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында вазыйфалар биләүдән тыю;

5) вәкаләтләре срогы тәмамланганчы даими нигездә вәкаләтләрен үтәүне тыю.

10. Җирле үзидарә депутатына карата "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7_3-1 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.

11. Әлеге статьяның 7.2 өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка

затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, "Аерым категорияләрдәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларны саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында" 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы Премьер-министры) күрсәтелгән затларга карата депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә бүтән җаваплылык чарасын куллану турында гариза белән тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яки судка мөрәҗәгать итә.

12. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында урнаштырыла һәм (яисә) массакүләм мәгълүмат чараларына муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару өчен бирелә.

### 33 статья. Җирлек Советы депутатының сайлаучылар белән үзара мөнәсәбәтләре

1. Җирлек Советы депутаты сайлаучылар, шулай ук предприятиеләр, оешмалар, дәүләт органнары һәм аның сайлау округы территориясендә урнашкан башка органнар белән элемтәдә тора.

2.Җирлек Советы депутаты сайлаучылар алдында җаваплы һәм алар алдында хисап тота.

3. Җирлек Советы депутаты сайлаучылар алдында үз эше турында елына кимендә бер тапкыр хисап тота, аларга Җирлек Советы эше турында даими рәвештә хәбәр итә, шулай ук аена кимендә бер тапкыр сайлаучыларны кабул итә.

4. Җирлек Советы депутаты Җирлектә яшәүчеләрнең законлы хокукларын, ирекләрен һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча законнарда каралган чараларны күрергә, шул исәптән алардан кергән тәкъдимнәрне, гаризаларны, шикаятьләрне карарга, аларда булган мәсьәләләрне дөрес һәм үз вакытында хәл итәргә тиеш.

Депутатларның сайлаучылар белән очрашулары биналарда, махсус каралган урыннарда, шулай ук ишегалдындагы территорияләрдә оештырылырга мөмкин, ләкин алар яшәү транспорт яки социаль инфраструктура, элемтә объектлары эшчәнлегенә комачаулык китермәскә, җәяүлеләрнең һәм (яки) транспорт чараларының хәрәкәтенә, гражданнарның торак урыннарына яки транспорт яисә социаль инфраструктура объектларына баруларына кыенлык тудырмаска тиеш. Мондый очрашулар турында Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органнары яки җирле үзидарә органнары хәбәр итү таләп ителми. Шул ук вакытта депутат күрсәтелгән органнарга аларны уздыру датасы һәм вакыты турында алдан хәбәр итәргә хокуклы.

6. Җирле үзидарә органнары депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус бирелгән урыннарны билгелиләр, шулай ук җирле үзидарә органнары депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен бирелә торган биналарның исемлеген һәм аларны бирү тәртибен билгелиләр.

7. Депутатның гавами чара рәвешендә сайлаучылар белән очрашулары җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә үткәрелә.

8. Депутатның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган гавами чара рәвешендә сайлаучылар белән очрашуларын оештыруга яисә уздыруга каршылык күрсәтү Россия Федерациясе законнары нигезендә административ җаваплылыкка китерә.

**34 статья. Яңа сайланган Җирлек Советы эшен оештыру**

1. Яңа чакырылыш Җирлек Советы беренче утырышы Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән саныннан депутатларның кимендә өчтән икесе сайланган көннән соң ун көннән дә соңга калмыйча җыела. Сайлаулардан соң беренче Җирлек Советы утырышын Җирлек башлыгы чакырта, ә ул булмаган очракта -Җирлекнең сайлау комиссиясе  чакырта.

2. Җирлек Советының сайлаулардан соң беренче утырышын яңа Җирлек башлыгы сайланганчы Җирлек Советының яше буенча иң өлкән депутаты ача һәм алып бара.

**35 статья. Җирлек Советы компетенциясе**

1. Җирлек советы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

1) Җирлек уставын кабул итү һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

2) Җирлек территориясендә законнар нигезендә гомуммәҗбүри кагыйдәләр билгеләү;

3) Җирлек бюджетын  раслауһәм аның үтәлеше турында хисап;

4) җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләү, үзгәртү һәм юкка чыгару, аларны түләү буенча салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә ташламалар бирү;

5) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау;

6) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә муниципаль программаларны раслау;

7) җирлекләрнең, шәһәр округларының коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программаларын, җирлекләрнең, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын, таләпләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган җирлекләрнең, шәһәр округларының социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын эшләү һәм раслау;

8) Җирлекнең чиген үзгәртү,  үзгәртеп кору турындагы инициатива күрсәтү;

9) Җирлек Советы депутатларын сайлауларын билгеләү һәм  Җирлек Советы депутатларын сайлаулар буенча сайлау округлары схемасын раслау;

10) җирле референдум билгеләү;

11) Җирлек башлыгын сайлау;

12)  Җирлек башлыгы урынбасарын сайлау;

13) Җирлек Советы депутатлары арасыннан муниципаль район Советына Җирлек вәкилен сайлау;

14) Җирлек Башкарма комитеты структурасын раслау, аның хезмәткәрләренең иң чик санын билгеләү;

15) Җирлек сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләп кую;

16) Җирлек Советы депутатының чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне билгеләү;

17) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукын гамәлгә ашыру;

18) Җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәткә идарә итү һәм аның белән эш итү тәртибен, шул исәптән федераль законнар нигезендә аны хосусыйлаштыру тәртибен һәм шартларын билгеләү; муниципаль мөлкәт төрләре исемлеген билгеләү, аны читләштерү Җирлек Советы тарафыннан килештереп яисә расланганнан соң башкарыла торган муниципаль мөлкәт төрләре исемлеген билгеләү;

19) муниципаль предприятиеләрне төзү, үзгәртеп оештыру һәм бетерү турында, шулай ук муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәтләренә тарифлар билгеләү, федераль законнарда каралган очраклардан тыш, эшләр башкару турында карарлар кабул итү тәртибен билгеләү;

20) Җирлекнең муниципальара хезмәттәшлек оешмаларында катнашу тәртибен билгеләү;

21) җирле үзидарә органнары эшчәнлеген матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү тәртибен билгеләү;

22) Җирлекнең Ревизия комиссиясен оештыру;

23) Җирлек башлыгын эштән читләштерү турында карар кабул итү;

24) җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен үтәвен тикшереп тору;

25) муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау;

26) Җирлекне территориаль планлаштыру документларын, җирлекне шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын, Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә башка шәһәр төзелеше документларын раслау;

27) Җирлек территориясендә торак пунктларның урамнарын һәм башка өлешләрен исемнәрен атау һәм үзгәртү турындагы мәсьәләләрне хәл итү;

28) гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен финанс һәм матди ресурсларның җирле резервларын булдыру һәм алардан файдалану тәртибен билгеләү;

29) муниципаль махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибен билгеләү;

30) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарына җирлек бюджетыннан кирәкле акчаларны бүлеп бирү шартларын һәм тәртибен билгеләү;

31) автоном коммерциягә карамаган оешмалар һәм фондлар рәвешендә коммерциягә карамаган оешмалар төзү турында карарлар кабул итү;

32) үз массакүләм мәгълүмат чараларын гамәлгә ашыру;

33) Җирлек Уставына һәм Җирлек Советы карарларына аңлатма бирү;

34) үз эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча Җирлек Советы регламентын һәм башка карарлар кабул итү;

35) Җирлек Советы аппараты турында Нигезләмәне раслау;

36) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән җирлекләрнең вәкиллекле органнары карамагына кертелгән башка вәкаләтләр, шулай ук әлеге Устав белән җирлек Советы компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләр.

2. Җирлек Советы Җирлек башлыгының, Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесенең, Җирлек Башкарма комитеты эшчәнлеге һәм Җирлек Башлыгы буйсынуында булган башка җирле үзидарә органнарының эшчәнлеге турында, шул исәптән Җирлек Советы тарафыннан куелган мәсьәләләрне хәл итү буенча еллык хисапларын тыңлый.

### 36 статья. Җирлек Советының эш тәртибе

1. Җирлек Советының эш тәртибе әлеге Устав һәм Җирлек Советы регламенты белән билгеләнә.

2. Җирлек Советы эшенең төп рәвеше аның утырышларыннан гыйбарәт, аларда Җирлек Советы компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр хәл ителә.

3. Җирлек Советы утырышлары анда сайланган депутатлар санының кимендә 50 проценты катнашканда хокуклы.

4. Җирлек Советының чираттагы утырышлары кирәк булган саен, әмма кимендә өч айга бер тапкыр уздырыла. Чираттан тыш утырышлар Җирлек башлыгы яисә Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән берен тәшкил иткән депутатлар төркеме инициативасы буенча чакырыла.

5. Совет утырышлары Җирлек Башлыгы тарафыннан чакырыла. Җирлек Советы депутатларына һәм чакырылган кунакларга чираттагы утырышның вакыты, урыны һәм көн тәртибе турында биш көннән дә соңга калмыйча, ә чираттан тыш утырышка - аны үткәрүгә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

6. Җирлек Советы утырышлары ачык һәм хәбәрдарлык рәвешендә уздырыла. Советның ачык утырышларында Җирлектә яшәүче һәркем катнашырга хокуклы.

Регламентта каралган очракларда, Җирлек Советы Җирлек Советы тарафыннан чакырылган затлар гына, шулай ук законнар нигезендә утырышта катнашырга хокукы булган затлар гына катнаша алган ябык утырыш уздыру турында карар кабул итәргә хокуклы.

7. Җирлек Советының һәр утырышында утырыш беркетмәсе алып барыла. Утырыш беркетмәсенә утырышны уздыру датасы, урыны һәм вакыты турындагы белешмәләр кертелә, карала торган барлык мәсьәләләр санап үтелә һәм, тавыш бирү йомгакларын күрсәтеп, кабул ителгән барлык карарлар теркәлә. Совет

утырышы беркетмәсенә имза салынганнан соң, Җирлектә яшәүче теләсә кайсы кеше аның белән танышырга мөмкин.

8. Җирлек Советы утырышларында һәр депутат бер тавышка ия. Җирлек Советы депутаты тавыш бирү хокукын шәхсән үзе гамәлгә ашыра. Җирлек Советы утырышларында тавыш бирү ачык (шул исәптән исемле) һәм яшерен булырга мөмкин. Тавыш бирүнең һәр төрен куллану очраклары әлеге Устав, Җирлек Советы регламенты белән билгеләнә.

**37 статья. Җирлек Советы эшчәнлеген оештыру**

1. Җирлек Советы эшчәнлеген Җирлек башлыгы оештыра.

2. Җирлек советы компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне алдан карау һәм әзерләү өчен Җирлек Советы регламенты нигезендә депутатлар арасыннан, Җирлек башлыгыннан тыш, даими яисә вакытлыча комиссияләр төзелергә мөмкин (яисә) күрсәтелгән мәсьәләләрне әзерләү өчен җаваплы депутатлар Җирлек Советы эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча билгеләнергә мөмкин. Депутат ике даими комиссиядә эшләргә хокуклы.

3. Җирлек Советы карамагындагы аеруча мөһим мәсьәләләр буенча фикер алышу, муниципаль программалар әзерләү, Җирлек Советы карарларын әзерләү, фикер алышу өчен Җирлек Советы каршында депутатлар, Җирлек Башкарма комитеты вәкилләре, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар һәм предприятиеләр, белгечләр, экспертлар һәм Җирлек халкы составындагы эшлекле, эксперт һәм башка киңәшмә төркемнәре төзелергә мөмкин.

**38 статья. Җирлек Советы тарафыннан контрольлек итү функцияләрен гамәлгә ашыру**

1. Җирлек Советы Җирлек территориясендә әлеге Устав нигезләмәләренең үтәлешен, Җирлек Советы тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актлар нигезләмәләренең үтәлешен, Җирлек бюджеты үтәлешен, бюджеттан тыш фондлар акчаларыннан файдалануны, Җирлекне үстерү программаларын, Җирлек Башкарма комитеты эшчәнлеген тикшереп тора.

2. Җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан законнар, әлеге Устав һәм башка муниципаль норматив хокукый актлар бозылу фактлары ачыкланган очракта, Җирлек Советы, Җирлек башлыгы карары белән күрсәтелгән фактларны тикшерү өчен депутатлар арасыннан вакытлы контроль комиссияләре төзелергә мөмкин.

3. Җирлек Советы, Җирлек башлыгы инициативасы буенча законнар нигезендә Җирлек бюджеты акчаларыннан максатчан файдалануны, муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген тикшерү (ревизия) уздырылырга мөмкин. Күрсәтелгән контроль һәм эксперт-аналитик чараларны үткәрү тәртибе Җирлекнең Ревизия комиссиясе турында Нигезләмә белән билгеләнә.

4. Җирлекнең башкарма комитеты, предприятие, учреждение, оешма, вазыйфаи затлар, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, әгәр закон белән башкасы билгеләнмәгән булса, Җирлек Советы, аның контроль комиссияләре депутаты, Җирлек Советы карамагына караган мәсьәләләр буенча соратып алынган мәгълүматны бирергә, ә законнар, муниципаль норматив хокукый актлар бозылган очракта, хокук бозуларны бетерү һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту өчен кичекмәстән чаралар күрергә тиеш.

5. Җирлек Советы Җирлек башлыгының Җирлек Башкарма комитеты һәм җирле үзидарәнең башка ведомство органнары эшчәнлеге турында, шул исәптән

Җирлек Советы куйган мәсьәләләрне хәл итү турында, еллык хисапларын тыңлый.

6. Җирлек Советы контроль функцияләрен башкарганда Җирлек Башкарма комитетының финанс-хуҗалык һәм башкарма-боеру эшчәнлегенә тыкшынырга хокуклы түгел.

## 39 статья. Җирлек вәкилен муниципаль район Советына сайлау

1. Арча муниципаль районы Советына Җирлек Советы депутатлары арасыннан яшерен тавыш бирү юлы белән Җирлек вәкиле сайлана.

2. Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән саныннан яртысыннан артыгы тавыш биргән кандидат Җирлек вәкиле булып сайланган дип санала.

## 40 статья. Җирлек Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Җирлек Советы вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

1) Җирлек Советының үз-үзен таркату турында карар кабул итүе;

2) “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 73 статьясында каралган нигезләрдә һәм тәртиптә Җирлек Советын тарату;

3) Җирлек Советы депутатларының әлеге составының хокуксызлыгы турында, шул исәптән депутатларның вәкаләтләре туктатылуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Югары суды карарының үз көченә керүе;

4) законнар нигезендә гамәлгә ашырыла торган Җирлекне үзгәртеп кору, шулай ук Җирлек бетерелгән очракта;

5) Җирлек чикләре үзгәрү нәтиҗәсендә сайлаучылар саны 25 проценттан арту;

6) гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен таләп ителгән муниципаль хокукый актны бастырып чыгару срогын бозу.

2. Җирлек Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату аның депутатларының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуга сәбәп була.

3. Җирлек Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, Җирлекнең Сайлау комиссиясе Федераль закон белән билгеләнгән срокларда вакытыннан алда Җирлек Советы депутатларын сайлауларны билгели, алар Федераль законда билгеләнгән срокларда үткәрелә.

## 41 статья. Җирлек Советының үз-үзен таркату турында карар кабул итү тәртибе

1. Җирлек Советының үз-үзен таркату турындагы карары Җирлек башлыгы яисә Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә яртысын тәшкил иткән депутатлар төркеме инициативасы белән кабул ителергә мөмкин.

2. Үз-үзен таркату турында карар кабул итү инициативасы түбәндәгечә күрсәтелә алмый:

1) Җирлек Советы сайланганнан соң беренче ел эчендә;

2) Җирлек бюджетын кабул итү һәм аның үтәлеше турында хисапны раслау чорында;

3) Җирлек башлыгын чакыртып алу турында тавыш бирүне уздыру чорында яки аның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта.

3. Җирлек Советының үз-үзен таркату турындагы язма тәкъдимендә үз-үзен таркату мотивлары булырга тиеш, шулай ук аңа таркату сәбәпләрен нигезләүче башка материаллар да өстәлергә мөмкин.

4. Җирлек Советы карары белән депутатлар арасыннан үз-үзен таркату турындагы мәсьәләне алдан карау өчен комиссия төзелә. Җирлек Советы яки Җирлек Башлыгы карары буенча Җирлек Советының үз-үзен таратуы турындагы мәсьәлә халык тыңлауларына чыгарылырга мөмкин.

5. Җирлек Советының үз-үзен таркату турындагы мәсьәләне карау дәвамлылыгы Җирлек Советы депутатлары һәм җирлек халкы тарафыннан үз-үзен таркату инициативасының барлык шартлары һәм нигезләмәләре буенча һәрьяклы һәм объектив фикер алышу мөмкинлеген гарантияләргә тиеш. Үз-үзен таркату турында карар үз-үзен таркату турындагы инициативаны тәкъдим иткән көннән ике ай узгач кабул ителергә мөмкин.

6. Җирлек Советының үз-үзен таркату турындагы карары Совет депутатларының билгеләнгән санынннан өчтән икесе тарафыннан яшерен тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

7. Җирлек Советының үз-үзен таркату турында тәкъдиме кире кагылган очракта, кабат үз-үзен таркату инициативасы үз-үзен таркату турындагы мәсьәлә буенча тавыш биргән көннән бер елдан да иртәрәк булмаган вакытта күрсәтелергә мөмкин.

**42 статья. Җирлек Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату**

1. Җирлек Советы депутаты вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) үлем;

2) үз теләге белән отставкага китү;

3) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылу;

4) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылу яисә вафат дип игълан ителү;

5) аңа карата судның гаепләү карары законлы көченә керү;

6) Россия Федерациясе чикләреннән даими яшәү урынына чыгу;

7) Россия Федерациясе гражданлыгын тукталу, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы, аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга, аларга чит ил гражданлыгын алырга йә аларга Россия Федерациясе гражданының Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы булмаган чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы чит ил гражданы яисә башка документ алу хокукына ия, аның нигезендә чит ил гражданы булган Россия Федерациясе гражданы чит ил гражданы, җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданлыгы тукталу;

8) сайлаучылар тарафыннан чакыртып алу;

9) Җирлек Советы вәкаләтләре вакытыннан алда тукталу;

10) хәрби хезмәткә чакырылу яисә аны алыштыра торган альтернатив граждан хезмәтенә китү;

11) федераль законнарда билгеләнгән башка очракларда.

2. Үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатның вәкаләтләре "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәгән очракта, вакытыннан алда туктатыла.

3. Җирлек Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында Җирлек Советы карары вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә, әгәр бу нигез Җирлек Советы утырышлары арасында барлыкка килсә - әлеге нигез барлыкка килгән көннән соң өч айдан да соңга калмыйча.

4. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 9 пунктында каралган очракта, Җирлек Советы депутаты вәкаләтләре Җирлек Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән туктатыла.

5. Җирлек Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, депутатны өстәмә сайлаулар федераль закон, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә билгеләнә.

## IV бүлек. Җирлек башлыгы

### 43 статья. Җирлек башлыгы - Җирлекнең иң югары вазыйфаи заты

1. Җирлек башлыгы Җирлекнең иң югары вазыйфаи заты булып тора.

Җирлек башлыгы Җирлек советы тарафыннан сайлана һәм аның рәисе булып тора.

3. Җирлек башлыгы вазыйфасының рәсми атамасы - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы.

4. Җирлек башлыгы вазыйфасы буенча Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге советы депутаты булып тора.

5. Җирлек башлыгы берүк вакытта Җирлек Советын һәм Җирлекнең башкарма комитетын җитәкли.

### 44 статья. Җирлек башлыгын сайлау тәртибе

1. Җирлек башлыгы Җирлек Советы депутатлары арасыннан яңа сайланган Җирлек Советының беренче утырышында яшерен тавыш бирү юлы белән сайлана, әгәр Совет тавыш бирүнең башка тәртибен билгеләмәсә, Җирлек Советы вәкаләтләре чорына сайлана.

Җирлек башлыгын сайлау Җирлек Советы депутатлары тәкъдим иткән кандидатлар арасыннан, шул исәптән Җирлектә яшәүчеләрнең, иҗтимагый берләшмәләрнең тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Җирлек Советы депутаты, әгәр аны сайлау өчен Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән саныннан яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, Җирлек башлыгы итеп сайланган була.

### 45 статья. Җирлек Башлыгы статусы

1. Җирлек башлыгы даими нигездә эшли.

2. Даими нигездә эшләгән Җирлек башлыгы Арча муниципаль районы Советында вазыйфага сайланган очракта, ул Җирлек башлыгы вәкаләтләрен төп эшчәнлегеннән азат ителмәгән нигездә башкара.

3. Җирлек Башлыгы үз эшчәнлегендә федераль закон һәм әлеге Устав нигезендә Җирлек халкына һәм Җирлек Советына хисап бирә һәм алар күзәтчелегендә.

4. Җирлек башлыгы Җирлек халкы һәм Җирлек Советы каршында үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән Җирлек Советы тарафыннан куелган мәсьәләләрне хәл итү турында елына бер тапкыр да кимрәк булмаган санда хисап тота.

5. Җирлек башлыгы "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен контрольдә тоту турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, "Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акча һәм (яисә) чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында" 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш.

**46 статья. Җирлек башлыгының вәкаләтләре**

Җирлек башлыгы:

1) Башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләрдә Җирлек исеменнән ышаныч кәгазеннән башка эш итә;

2) Җирлек Советы эшен оештыра, Җирлек Советы утырышларын чакыра һәм аларда рәислек итә;

3) әлеге Устав белән билгеләнгән тәртиптә Җирлек Советы кабул иткән хокукый актларга кул куя һәм халыкка җиткерә;

4) Җирлек Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча үз вәкаләтләре чикләрендә хокукый актлар чыгара;

5) Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт төзи;

6) Җирлек Советы эшендә җәмәгатьчелек фикерен ачыклауны һәм исәпкә алуны тәэмин итү чараларын күрә;

7) гражданнарны кабул итүне, аларның мөрәҗәгатьләрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карауны оештыра;

8) Җирлек Советының утырышлар беркетмәләренә имза сала;

9) Җирлек Советы аппараты эше белән җитәкчелек итә;

10) Җирлек Советының контроль вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны җайга сала;

11) Җирлек Советын тоту һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү өчен Җирлек бюджетында каралган чыгымнар буенча акча бүлүче булып тора;

12) закон һәм әлеге Устав нигезендә гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру буенча Җирлек Советының хокукый актын кабул итүне оештыра;

13) җирлекләрнең федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, башка федераль органнар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирлек территориясендә гамәлдә булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән кирәкле хезмәттәшлеген тәэмин итә;

14) Җирлек исеменнән икътисади һәм социаль-мәдәни өлкәләрдә хезмәттәшлек турында дәүләт хакимияте органнары, башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән шартнамәләр һәм килешүләр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлек турында шартнамәләр һәм килешүләр төзи;

15) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән муниципаль берәмлекләр башлыклары карамагына кертелгән башка вәкаләтләрне, шулай ук әлеге Устав, Җирлек башлыгы компетенциясенә Җирлек Советы карарлары тарафыннан кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

16) әлеге Устав нигезендә муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органын билгели;

17) “Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 2 - 5 өлешләре нигезендә проектның нәтиҗәлелеген бәяләүне уздыру һәм аның чагыштырма өстенлеген билгеләү өчен муниципаль-хосусый партнерлык проекты җибәрә.

**47 статья. Җирлек башлыгының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату**

1. Җирлек башлыгының вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) үлем;

2) үз теләге белән отставкага китү;

3) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 74.1 статьясы нигезендә отставкага җибәрү;

4) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 74 статьясы нигезендә вазыйфаданваз кичү. Әгәр вазыйфалары Россия Федерациясе субъекты югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасыннан читләштерү турындагы хокукый акты нигезендә яисә муниципаль берәмлек башлыгын отставкага җибәрү турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары нигезендә вакытыннан алда туктатылган муниципаль берәмлек башлыгы әлеге хокукый актка яки карарга шикаять белдерсә, муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы суд карары үз көченә кергәнче муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан үз составыннан яисә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатлар арасыннан сайлана торган муниципаль берәмлек башлыгын сайлау турында карар кабул итәргә хокуклы түгел;

5) суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылу. Җирлек башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан үз составыннан сайлана торган Җирлек башлыгын сайлау вәкаләтләр туктатылган көннән алып алты айдан да соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Шул ук вакытта, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре чоры тәмамланганчы алты айдан да кимрәк вакыт калган булса, Җирлек башлыгын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы составыннан сайлау яңа сайланган муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының беренче утырышында гамәлгә ашырыла;

6) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылу яисә вафат дип игълан ителү;

7) аңа карата судның гаепләү карары законлы көченә керү;

8) Россия Федерациясе чикләреннән даими яшәү урынына чыгу;

9) Россия Федерациясе гражданлыгын тукталу, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы, аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга, аларга чит ил гражданлыгын алырга йә аларга Россия Федерациясе гражданының Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы булмаган чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы чит ил гражданы яисә башка документ алу хокукына ия, аның нигезендә чит ил гражданы булган Россия Федерациясе гражданы чит ил гражданы, җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданлыгы тукталу;

10) сайлаучылар тарафыннан чакыртып алу;

11) суд тәртибендә сәламәтлеге торышы буенча Җирлек башлыгы вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга сәләтсез дип танылу;

12) “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә Җирлек үзгәртеп корылган, шулай ук бетерелгән очракта;

13) муниципаль берәмлек чикләрен үзгәртү аркасында сайлаучылар саны 25 проценттан арту;

14) гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен таләп ителә торган муниципаль хокукый актны бастырып чыгару срогын бозу;

15) "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәү.

2. Җирлек башлыгының вәкаләтләре әлеге статьяның 1 өлешендәге 1-11, 14 һәм 15 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча вакытыннан алда туктатылган очракта, яңа башлык сайлау Җирлек Советының якындагы утырышында гамәлгә ашырыла.

3. Җирлек башлыгының вәкаләтләре Җирлек Советының вәкаләтләре чоры тәмамланганчы алты айдан да кимрәк вакыт кала туктатылса, Җирлек Советы карары буенча яңа Башлык сайлау үткәрелмәскә мөмкин.

### 48 статья. Җирлек башлыгы урынбасары

1. Җирлек башлыгы тәкъдиме буенча Җирлек Советы депутатлары арасыннан Җирлек башлыгы урынбасары сайлана. Җирлек башлыгы урынбасары яшерен яисә ачык тавыш бирү юлы белән сайлана. Тавыш бирү ысулын сайлау турындагы карар Җирлек Советы карары белән билгеләнә.

2. Җирлек башлыгы Җирлек Советына бушатылган нигездә ике урынбасар һәм бушатылмаган нигездә ике урынбасар сайларга тәкъдим итәргә хокуклы.

3. Җирлек Советы депутаты, әгәр аны сайлау өчен Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санының яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, Җирлек башлыгының сайланган урынбасары булып санала.

4. Җирлек башлыгы урынбасары Җирлек Советы регламентында билгеләнгән вазыйфаларны бүлү нигезендә билгеләнгән вазыйфаларны үти, Җирлек башлыгы йөкләмәләрен үти, ә ул вакытлыча (авыруга яисә отпускка бәйле) булмаган очракта, яисә суд карары буенча сак астына алу рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чараларын куллану яисә вазыйфасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату очрагында, Җирлек башлыгы вазыйфаларын башкара.

5. Җирлек башлыгы урынбасарының вәкаләтләре әлеге Уставның 39 статьясында каралган нигезләр буенча вакытыннан алда туктатыла.

6. Җирлек башлыгы урынбасары Җирлек башлыгы инициативасы буенча кабул ителә торган Җирлек Советы карары яисә Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән бере күләмендә депутатлар төркеме таләбе буенча вазыйфадан теләсә кайсы вакытта чакыртып алынырга мөмкин. Җирлек башлыгы урынбасарын чакыртып алу турындагы карар Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

7. Җирлек башлыгы урынбасары законнарда билгеләнгән бурычларны, тыюларны һәм чикләүләрне үтәргә тиеш.

## V бүлек. Җирлекнең Башкарма комитеты

### 49 статья. Җирлек Башкарма комитеты - җирле үзидарәнең башкарма-боеру органы

1. Җирлек Башкарма комитеты җирле үзидарәнең башкарма-боеру органы булып тора.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирлек-Башкарма комитетының рәсми исеме - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге башкарма комитеты.

3. Җирлек Башкарма комитеты Җирлек советына хисап тота һәм аның күзәтчелегендә була.

4. Җирлек Башкарма комитетының гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән Россия Федерациясе гербы сурәте төшерелгән түгәрәк мөһере, үз исеме язылган бланклары, мөһере бар.

5. Җирлек Башкарма комитеты эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары Җирлек бюджетында Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

**50 статья. Җирлек Башкарма комитеты структурасы**

1. Башкарма комитет структурасы Җирлек башлыгы тәкъдиме буенча Җирлек Советы тарафыннан раслана.

2. Җирлек  Башкарма комитеты структурасына түбәндәгеләр керә: Башкарма комитет җитәкчесе - Җирлек башлыгы, Башкарма комитет секретаре, Башкарма комитетның башка вазыйфаи затлары.

**51 статья. Башкарма комитет вәкаләтләре**

1. Җирлек  Башкарма комитеты:

1) планлаштыру, бюджет, финанс һәм исәпкә алу өлкәсендә:

- Җирлек бюджетын эшли;

- Җирлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясен эшләүне тәэмин итә;

- Җирлекнең бюджетын үтәүне оештыра, җирлекнең социаль-икътисадый үсеш планнарын һәм стратегиясен үтәүне оештыра;

- бюджетның үтәлеше турында, җирлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясенең үтәлеше турында хисаплар әзерләүне тәэмин итә;

- стратегик планлаштыру өлкәсендә «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

- Җирлекнең икътисады һәм социаль өлкәсе торышын чагылдыра торган статистик күрсәткечләрне җыюны оештыра һәм күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнарына Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә тапшыру эшен оештыра;

2) җирлек территориясендә муниципаль милеккә идарә, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләр өлкәсендә:

- Җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәт белән идарә итә, муниципаль милек объектларын төзү, сатып алу, алардан файдалану, кушу һәм арендалау мәсьәләләрен хәл итә;

- Җирлек Советы карары белән билгеләнә торган очракларда муниципаль мөлкәтне читләштерү турында тәкъдимнәрне, шул исәптән аны хосусыйлаштыру турында тәкъдимнәрне Совет тарафыннан килештерүгә (раслауга) кертә;

- Җирлекнең икътисадый һәм социаль үсешендә муниципаль милектәге предприятиеләр, оешмалар белән хезмәттәшлек турында шартнамәләр төзи; җирлек территориясендә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә төрле милек рәвешләрендәге предприятиеләр төзүгә ярдәм итә;

- Җирлек Советы билгеләгән тәртип нигезендә муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр төзи, аларның эшчәнлек максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели, аларның уставларын раслый, муниципаль казна учреждениеләрен финанслауны тәэмин итә, муниципаль учреждениеләрне һәм предприятиеләрне үзгәртеп оештыру һәм бетерү мәсьәләләрен хәл итә, контракт нигезендә билгели һәм аларның җитәкчеләрен биләгән вазыйфасыннан азат итә;

- муниципаль казна учреждениеләре эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итә һәм бюджет һәм автоном муниципаль учреждениеләр тарафыннан муниципаль

биремнәрне финанс белән тәэмин итә, шулай ук муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып ала;

- муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар һәм, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан башкарыла торган эшләр билгели;

3) авыл хуҗалыгын һәм эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә:

- авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтү өчен шартлар тудыра;

- кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыра;

4) халыкка торак-коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә:

- халыкны җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра; базарлар һәм ярминкәләр оештыра;

- торак законнары нигезендә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнарга бирә;

- мәдәният оешмаларының ялын оештыру һәм халыкны хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

- Җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

- Җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

- Җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыра һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, моңа гражданнарның су объектларына ирекле керүен тәэмин итү дә керә;

- энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә муниципаль программаларны гамәлгә ашыра, муниципаль берәмлек чикләрендә муниципаль торак фонды тәшкил итә торган күпфатирлы йортларга энергетика тикшерүен уздыруны оештыра, энергияне сак тоту турындагы һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турындагы законнарда каралган башка чаралар оештыра һәм үткәрә;

- Җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эшчәнлекне гамәлгә ашыра;

5) төзекләндерү өлкәсендә:

- каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортта ташу эшчәнлеген оештыруда катнаша;

- Җирлекне төзекләндерү кагыйдәләренең үтәлешен тикшереп тора, җирлек территориясен төзекләндерү эшчәнлеген оештыра (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, урамнар исемнәре һәм йортларның номерлары булган күрсәткечләр урнаштыруны, кече архитектура формаларын урнаштыруны һәм тотуны да кертеп);

- адрес объектларына адреслар бирә, адресларны үзгәртә, юк итә, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге җирле юлларыннан тыш), җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исем бирә, мондый исемнәрне үзгәртә, юк итә, мәгълүматны дәүләт адреслы реестрында урнаштыра;

- үзбелдекле төзелгән корылманы җимерү, үзбелдекле төзелгән корылманы җимерү яисә билгеләнгән таләпләргә туры китерү турындагы карарны Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә кабул итә;

6) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау, законлылыкны тәэмин итү, халыкны һәм территорияне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә:

- Җирлек территориясендә законнарның, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә актларының үтәлешен, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклауны тәэмин итә;

- дәүләт хакимияте органнарының һәм дәүләт вазыйфаи затларының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның җирле үзидарә хокукларын боза торган актларына билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән судта яисә арбитраж судта шикаять бирә;

- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын үткәрүне тәэмин итә;

- җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыруга ярдәм итә;

7) мәдәният, спорт һәм балалар һәм яшьләр белән эшләү өлкәсендә:

-Җирлек территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклауны, алардан файдалануны һәм аларны популярлаштыруны тәэмин итә;

- җирле традицион халык сәнгать иҗатын үстерү өчен шартлар тудыра, җирлектә халык сәнгать һөнәрләрен саклап калуда, торгызуда һәм үстерүдә катнаша;

- Җирлек территориясендә урнашкан муниципаль музейларның карап тотуны тәэмин итә;

- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра.

8) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкару өлкәсендә :

- Җирлекнең җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

- дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган матди һәм финанс чараларының исәбен алып бара һәм алардан тиешенчә файдалануны тәэмин итә;

- тиешле федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисаплар тапшыра;

- Җирлекнең җирле үзидарә органнары карамагындагы матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан аларга тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен өстәмә файдалануны Җирлек Советы карарлары нигезендә тәэмин итә;

9) башка вәкаләтләр:

- Җирлек ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итә, ачык аукцион уздыруны "Федераль милектәге су объектларында төзелгән ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукын бирә;

- Җирлек башлыгының эшчәнлеген оештыру, хокукый, мәгълүмати, матди-техник һәм башка төрле тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

- Җирлекнең архив фондларын булдыруны тәэмин итә;

- Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү максатларында гражданнарны әлеге Уставның 5 статьясындагы 1 өлешенең 8 - 10, 17 һәм 20 пунктларында каралган җирлек өчен әһәмиятле булган социаль әһәмиятле эшләрне (шул исәптән дежур тору) иракле рәвештә башкаруга җәлеп итү турында карар кабул итә, аларны үткәрүне оештыра;

- Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча башка вәкаләтләрне, законнарда, әлеге Устав тарафыннан кертелгән вәкаләтләрдән тыш, Җирлек Советы яисә җирле үзидарәнең башка органнары компетенциясенә җирлек Советы карарлары белән гамәлгә ашыра.

10) муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендә Җирлек Башкарма комитеты түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

- муниципаль-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү;

- муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү төзү хокукына конкурслар уздыру өчен конкурс документациясен гавами партнерга килештерү;

- муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүне гамәлгә ашыруны мониторинглау;

- муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүне гамәлгә ашыру барышында гавами партнерларның һәм хосусый партнерларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауда ярдәм итү;

- муниципаль-хосусый партнерлык турында төзелгән килешүләр реестрын алып бару;

- муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү хакында мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү;

- муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүне гамәлгә ашыру мониторингы нәтиҗәләрен вәкаләтле органга тапшыру;

- 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм норматив хокукый актлары, әлеге устав белән җирлекнең муниципаль хокукый актларында каралган башка вәкаләтләр.

2. Җирлек Башкарма комитеты Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

- Җирлек музейларын төзи;

- Җирлектә нотариус булмаган очракта, законнарда каралган нотариаль гамәлләр башкара;

- опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруда катнаша;

-Җирлек территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра;

- Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм җирлек территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыруга ярдәм итә;

- Җирлек территориясендә урнашкан муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү чараларын оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнаша;

- муниципаль янгын сагын төзи;

- туризмны үстерү өчен шартлар тудыра;

- кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контролен гамәлгә ашыручы һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга булышлык күрсәтүче иҗтимагый күзәтү комиссияләренә ярдәм күрсәтә.

- 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” Федераль закон нигезендә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук инвалидларның гомумроссия иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оешмаларга ярдәм күрсәтә;

- гражданнарга социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондының торак урыннарын торак законнары нигезендә бирә;

- Җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эшчәнлекне гамәлгә ашыра;

- «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыра;

- инвалидларның, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын, җайлашу физик культурасын һәм җайлашу спортын үстерүгә ярдәм итә;

“Кулланучылар хокукларын яклау турында” 1992 елның 7 февралендәге 2300-I номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра;

- участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр әлеге вазыйфаны биләгән вакытка торак урыны бирә;

- алкоголь, наркотик кулланган  яки башкача токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыра.

3. Җирлек  Башкарма комитеты муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган була.

Муниципаль контроль өлкәсендәге Җирлек Башкарма комитеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) тиешле территориядә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) җирле үзидарә органнарына тапшырылган гамәлгә ашыру вәкаләтләрен региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру;

3) эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентларын эшләү, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары тарафыннан раслана торган типовой административ регламентлар нигезендә җирле үзидарә органнарына вәкаләтләр бирелгән региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруның административ регламентларын эшләү. Күрсәтелгән административ регламентларны эшләү һәм кабул итү Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла;

4) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең күрсәткечләр һәм аны үткәрү методикасы тарафыннан расланган эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контроль нәтиҗәлелеген мониторинглау оештыра һәм уздыра;

5) федераль законнарда, Татарстан Республикасы субъектлары законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

Җирлекнең башкарма комитеты органнарына муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыру функцияләре мондый органнарның статусын билгеләүче хокукый актлар нигезендә йөкләнергә мөмкин.

Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, тикшерүләр оештыру һәм үткәрү белән бәйле мөнәсәбәтләргә карата 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында” Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

## VI бүлек. Җирле үзидарәнең башка органнарының үзара хезмәттәшлеге

### 52 статья. Җирлекнең ревизия комиссиясе

1. Җирлекнең Ревизия комиссиясе җирле үзидарәнең даими эшләүче коллегиаль органы булып тора.

2. Җирлекнең Ревизия комиссиясе рәистән һәм ике әгъзадан тора.

Җирлекнең Ревизия комиссиясен оештыру һәм аның эшчәнлеге тәртибе, вәкаләтләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы, "Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында" 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Җирлекнең Ревизия комиссиясе турындагы Нигезләмә белән билгеләнә.

Федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә Ревизия комиссиясе оештыру һәм аның эшчәнлеген хокукый җайга салу шулай ук Татарстан Республикасы законнары белән гамәлгә ашырыла.

### 53 статья. Җирлек Советының, Җирлек башлыгының, Җирлек Башкарма комитетының һәм җирле үзидарәнең башка органнарының үзара мөнәсәбәтләре нигезләре

1. Әлеге Уставта билгеләнгән вәкаләтләрне бүлү нигезендә Җирлек Советы, Җирлек башлыгы һәм Җирлек Башкарма комитеты үз вәкаләтләрен мөстәкыйль башкара.

2. Җирлек Советы һәм Халыкның башкарма комитеты  Җирлекнең икътисадый һәм социаль үсеше процесслары белән нәтиҗәле идарә итү максатларында һәм аның халкы мәнфәгатьләрендә законнарда, әлеге Устав билгеләгән рәвешләрдә үзара хезмәттәшлек итәргә тиеш.

3. Җирлек Советы һәм Җирлек башкарма комитеты кабул ителгән норматив хокукый актларны имзаланган көннән алып җиде көн эчендә бер-берсенә юллыйлар.

4. Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе буларак Җирлек башлыгы  Җирлек Советының, Җирлек башлыгының хокукый актларын кабул итү, бетерү, үзгәртү турындагы тәкъдим белән Җирлек Советына мөрәҗәгать итәргә, шулай ук аларга суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

5. Җирле үзидарәнең башка органнарының үзара эшчәнлек тәртибе Җирлек Советы тарафыннан билгеләнә ала.

### 54 статья. Җирле үзидарә органнары арасында бәхәсләрне хәл итү

Җирле үзидарә органнары арасында аларның вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча бәхәсләр килештерү процедуралары уздыру юлы белән яисә суд тәртибендә хәл ителә.

## VII бүлек. Сайлау комиссиясе

### 55 статья. Җирлек Сайлау комиссиясе

1. Җирлек Сайлау комиссиясе муниципаль сайлауларны, җирле референдумны, депутатны чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны, муниципаль җирлекнең чикләрен үзгәртү, муниципаль җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне оештыра.

2. Җирлек Сайлау комиссиясе җирле үзидарә органнары структурасына керми торган муниципаль орган.

3. Җирлек Сайлау комиссиясе Җирлек Советы тарафыннан федераль законнарда, Татарстан Республикасы Сайлау кодексында билгеләнгән тәртиптә төзелә.

4. Сайлау комиссиясе вәкаләтләре вакыты биш ел.

5. Җирлек Сайлау комиссиясе хәлиткеч тавыш хокукына ия 6 әгъзадан тора.

6. Җирлек Сайлау комиссиясе эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү Җирлек бюджетында Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

7. Җирлек Советы тарафыннан расланган Җирлек Сайлау комиссиясе вәкаләтләре, аның эшчәнлеге тәртибе һәм гарантияләре федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Җирлек Советы тарафыннан расланган Җирлек сайлау комиссиясе турында Нигезләмә белән җайга салына. Җирлек Советы мөрәҗәгате нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча Җирлек сайлау комиссиясе вәкаләтләре территориаль сайлау комиссиясенә йөкләнергә мөмкин.

## VIII бүлек. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ГРАЖДАН-ХОКУКЫЙ ҺӘМ ФИНАНС НИГЕЗЛӘРЕ

### 56 статья. Юридик зат хокукына ия җирле үзидарә органнары

1. Федераль закон һәм әлеге Устав нигезендә юридик зат хокукына Җирлек Советы һәм Җирлек башкарма комитеты ия.

2. Юридик зат хокуклары Җирлек Советы карары буенча башкарма комитет структурасы нигезендә Җирлек башкарма комитетының аерым органнарына бирелергә мөмкин.

### 57 статья. Юридик затлар буларак җирле үзидарә органнары

1. Җирлек башлыгы Җирлек исеменнән мөлкәти һәм башка хокуклар һәм бурычлар алырга һәм гамәлгә ашырырга, судта ышанычнамәсез чыгыш ясарга мөмкин.

2. Җирлекнең юридик зат хокуклары бирелгән җирле үзидарә органнары идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыру өчен төзелә торган муниципаль казна учреждениеләре булып тора һәм федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә юридик зат буларак дәүләт теркәве узарга тиеш.

### 58 статья. Җирлекнең җирле үзидарә органнарын финанслау

Җирле үзидарә органнары эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү Җирлекнең фәкать үз керемнәре исәбеннән генә гамәлгә ашырыла.

## IX бүлек. ҖИРЛЕК БАШЛЫГЫНА ҺӘМ ҖИРЛЕКНЕҢ БАШКА ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНА БИРЕЛӘ ТОРГАН СОЦИАЛЬ ҺӘМ БАШКА ГАРАНТИЯЛӘР

### 59 статья. Җирлек башлыгына һәм Җирлекнең башка вазыйфаи затларына бирелә торган социаль һәм башка гарантияләр

1. Җирлек башлыгының һәм Җирлекнең башка вазыйфаи затларының социаль һәм башка гарантияләре "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлек вәкиллекле органы депутатының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында" 2009

елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Җирлек Советы карарлары нигезендә билгеләнә.

2. Җирлек башлыгының һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның еллык түләүле отпускы төп түләүле отпusktan һәм өстәмә түләүле отпусктан гыйбарәт.

3. Җирлек башлыгына һәм муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга 30 календарь көн дәвамлылыгы белән еллык төп түләүле отпуск билгеләнә.

### 60 статья. Җирлек Советы депутаты, башка вазыйфаи затлар эшчәнлегенең социаль һәм башка гарантияләре

1. Җирлек Советы һәм аның органнары утырышларында катнашу, Совет йөкләмәләрен үтәү чорында азат ителмәгән нигездә эшләүче Җирлек Советы депутатына әлеге законнарда каралган акчалата компенсация һәм башка түләүләр түләнә.

2. Үз вәкаләтләрен азат ителмәгән нигездә гамәлгә ашыручы Җирлек башлыгы урынбасарына, әлеге Уставта каралган очракларда, Җирлек башлыгы вазыйфаларын үтәгәндә, Җирлек башлыгының айлык акчалата хезмәт хакының 90% күләмендә түләнә.

3. Җирлекнең Ревизия комиссиясе, Җирлек сайлау комиссиясе әгъзаларына әлеге органнар эшендә катнашу вакытына Җирлек Советы карарлары нигезендә акчалата компенсация түләнә.

### 61 статья. Җирлек башлыгының, Җирлек Советы депутатларының кагылгысызлык гарантияләре

1. Җирлек Советы депутатларының, шул исәптән Җирлек башлыгының кагылгысызлык гарантияләре аларны җинаять яисә административ җаваплылыкка җәлеп иткәндә, тоткарлаганда, кулга алганда, тентү, сорау алганда, аларга карата башка җинаять-процессуаль һәм административ-процессуаль гамәлләр кылганда, шулай ук алар биләгән торак һәм (яисә) хезмәт урыны, багажы, шәхси һәм хезмәт транспорт чаралары, алар тарафыннан файдаланыла торган элемтә чараларына карата оператив-эзләнү чаралары үткәргәндә федераль законнар белән билгеләнә.

2. Җирлек Советы депутаты федераль закон нигезендә әйткән фикере, тавыш биргәндә чагылдырылган позициясе, аның статусына туры килә торган башка гамәлләре өчен, шул исәптән вәкаләтләре чоры тәмамланганнан соң, җинаять яисә административ җаваплылыкка тартыла алмый. Әлеге нигезләмә Җирлек Советы депутаты тарафыннан гавами кимсетүләр, яла ягу яисә федераль законда каралган башка хокук бозу очракларына кагылмый.

## X бүлек. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫНЫҢ ҺӘМ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

### 62 статья. Җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының җаваплылыгы

Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары Җирлек халкы, дәүләт, физик һәм юридик затлар алдында законнар нигезендә җаваплы.

### 63 статья. Җирлек Советы депутатларының халык алдында җаваплылыгы

1. Җирлек Советы депутатларының, шул исәптән Җирлек башлыгының, халык алдында җаваплылыгы аны сайлаган кешеләрнең ышанычын югалту нәтиҗәсендә барлыкка килә.

2. Җирлек халкының ышанычын югалткан депутат, шул исәптән Җирлек башлыгы, әлеге Устав тарафыннан каралган нигезләрдә һәм тәртиптә чакыртып алынырга мөмкин.

## 64 статья. Җирлекнең җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларның дәүләт алдында җаваплылыгы

1. Җирлек Советының, Җирлек башлыгының дәүләт алдында җаваплылыгы Россия Федерациясе Конституциясен, федераль конституциячел законнарны, федераль законнарны, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы законнарын һәм әлеге Уставын бозган очракта, шулай ук җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен тиешенчә гамәлгә ашырмаган очракта, суд карары нигезендә барлыкка килә.

2. Җирлек Советын таркату, Җирлек башлыгы, Җирлек башкарма комитеты җитәкчесен вазыйфасыннан читләштерү һәм отставкага җибәрү нигезләре һәм тәртибе "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнә.

## 65 статья. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны ышаныч югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү (вазыйфасыннан азат итү)

1. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, муниципаль норматив хокукый актларда каралган тәртиптә ышаныч югалтуга бәйле рәвештә түбәндәге очракларда эштән азат ителергә (вазыйфасыннан азат ителергә) тиеш:

1) зат тарафыннан үзе бер ягы булып торган мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм (яки) җайга салу буенча чаралар күрмәү;

2) үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне тапшырмау яисә белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшыру;

3) затның, федераль законда билгеләнгән очраклардан тыш, коммерция оешмасының идарә органы эшчәнлегендә түләүле нигездә катнашуы;

4) эшкуарлык эшчәнлеген башкару;

5) затның Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, чит ил коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган оешмаларының һәм Россия Федерациясе территориясендә аларның структур бүлекчәләренең башка органнары составына керүе.

2. Үзенә буйсынган затның мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында билгеле булган муниципаль вазыйфаны биләүче зат, ышаныч югалтуга бәйле рәвештә эштән чыгарылырга (вазыйфасыннан азат ителергә) тиеш, шулай ук муниципаль вазыйфаны биләп торучы зат тарафыннан үзенә буйсынган затның мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмавы һәм (яки) аны җайга салу буенча чаралар күрелмәгән очракта.

### 66 статья. Җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларның физик һәм юридик затлар каршында җаваплылыгы

Җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының физик һәм юридик затлар алдындагы җаваплылыгы федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә барлыкка килә.

## XI бүлек. ҖИРЛЕКНЕҢ МУНИЦИПАЛЬ ХОКУКЫЙ АКТЛАРЫ

### 67 статья. Җирлекнең муниципаль хокукый актлары системасы

1. Җирлекнең муниципаль хокукый актлары системасына түбәндәгеләр керә:

1) Җирлек уставы, җирле референдумда кабул ителгән хокукый актлар;

2) Җирлек Советының норматив һәм башка хокукый актлары;

3) Җирлек башлыгының, башкарма комитетның һәм җирле үзидарәнең әлеге Уставта каралган башка органнарының һәм вазыйфаи затларының норматив һәм башка хокукый актлары.

2. Җирлек уставы һәм җирле референдумда кабул ителгән хокукый актлар рәвешендә рәсмиләштерелгән карарлар муниципаль хокукый актлар системасында иң югары юридик көч актлары булып тора, турыдан-туры гамәлдә була һәм Җирлекнең бөтен территориясендә кулланыла.

Башка муниципаль хокукый актлар әлеге Уставка һәм җирле референдумда кабул ителгән хокукый актларга каршы килмәскә тиеш.

3. Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары кабул иткән муниципаль хокукый актлар Җирлекнең бөтен территориясендә һичшиксез үтәлергә тиеш.

4. Әлеге органнар яисә тиешле вазыйфалар юкка чыгарылган яисә әлеге органнарның яисә вазыйфаи затларның вәкаләтләре исемлеге үзгәртелгән очракта, вәкаләтләренә муниципаль хокукый актны кабул итү (бастырып чыгару) кертелгән җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан муниципаль хокукый актлар юкка чыгарылырга яисә аларның гамәлләре тиешле муниципаль хокукый актны кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органнары яисә вазыйфаи затлары тарафыннан туктатылырга мөмкин, шулай ук суд тарафыннан, ә җирле үзидарә органнарының федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны җайга сала торган өлешендә-Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан.

5. Норматив характерга ия булмаган муниципаль хокукый актның гамәлдә булуы, эшкуарлар хокукларын яклау буенча Россия Федерациясе Президенты каршындагы вәкаләтле вәкилнең эшкуарлар хокукларын яклау буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән тиешле күрсәтмәне алган очракта, аны чыгарган җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи заты тарафыннан кичекмәстән туктатыла. Алынган күрсәтмәнең үтәлеше турында Җирлек башкарма комитеты яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә өч көн эчендә, ә Җирлек Советына - карар кабул иткән көннән алып өч көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

### 68 статья. Гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарлар

1. Җирлектә яшәүчеләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча карары гражданнарның җирле референдумда турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Әгәр Җирлектә яшәүчеләрнең турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль норматив хокукый акт кабул итү (бастырып чыгару) таләп ителсә, компетенциясенә күрсәтелгән актны кабул итү (бастырып чыгару) кергән җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарә органы вазыйфаи заты референдумда кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән 15 көн эчендә тиешле муниципаль норматив хокукый актны әзерләү һәм (яисә) кабул итү вакытын билгеләргә тиеш. Күрсәтелгән срок өч айдан да артмаска тиеш.

3. Муниципаль норматив хокукый актның гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарныбастырып чыгару срогын үтәмәү Җирлек башлыгын чакыртып алу яисә Җирлек Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату өчен нигез булып тора.

**69 статья. Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актларның төрләре**

1. Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү йөзеннән түбәндәге муниципаль хокукый актлар чыгара:

1) Җирлек Советы - Җирлек Советы карарлары;

2) Җирлек башлыгы - Җирлек башлыгы карары һәм күрсәтмәләре;

2. Җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затлары әлеге Уставта, аларның статусын билгеләүче башка муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән үз вәкаләтләре чикләрендә күрсәтмәләр һәм боерыклар чыгара.

**70 статья. Муниципаль хокукый актларны әзерләү**

1. Муниципаль хокукый актлар проектлары Җирлек башлыгы, Җирлек Советы депутатлары, Арча районы прокуроры, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициатив төркемнәре, шулай ук аны алып бару мәсьәләләре буенча Җирлекнең Ревизия комиссиясе тарафыннан кертелергә мөмкин.

2. Арча районы прокуроры, үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру барышында гамәлдәге муниципаль норматив хокукый актларны камилләштерү кирәклеген билгеләгәндә, муниципаль норматив хокукый актларны үзгәртү, гамәлдән чыгару яисә кабул итү турында тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

3. Муниципаль хокукый актлар проектларын кертү тәртибе, аларга теркәлә торган документларның исемлеге һәм формасы Җирлек Советы регламенты һәм Җирлек башлыгы тарафыннан билгеләнә.

**71 статья. Җирлек Советы хокукый актлары**

1. Җирлек Советы федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Устав белән аның компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча Җирлек территориясендә үтәлергә тиешле кагыйдәләрне билгели торган карарлар, Җирлек башлыгын отставкага җибәрү турында карар, шулай ук Җирлек Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав белән аның компетенциясенә кергән башка мәсьәләләр буенча карарлар кабул итә.

2. Җирлек территориясендә үтәү өчен мәҗбүри булган кагыйдәләрне билгели торган Җирлек Советы карарлары, әгәр федераль законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санынnан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3. Җирле салымнар һәм җыемнар билгеләүне, үзгәртүне һәм юкка чыгаруны, Җирлек бюджеты акчаларыннан чыгымнарны гамәлгә ашыруны күздә тоткан Җирлек Советы карарлары Җирлекнең башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы буенча яисә аның бәяләмәсе булганда гына Җирлек Советы каравына кертелергә мөмкин. Күрсәтелгән бәяләмә Җирлек Советы регламентында билгеләнгән тәртиптә утыз көн эчендә Җирлек Советына тапшырыла.

4. Җирлек Советы карарларына алар кабул ителгән көннән алып өч көн эчендә Җирлек башлыгы тарафыннан имза салына һәм әлеге Уставта билгеләгән тәртиптә халыкка җиткерелә.

5. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарларын кабул иткәндә муниципаль берәмлек башлыгы тавышы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.

### 72 статья. Җирлек башлыгының хокукый актлары

Җирлек башлыгы үз вәкаләтләре чикләрендә законнарда, әлеге Уставта, Җирлек Советы карарларында билгеләнгән Җирлек Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча карар һәм күрсәтмәләр, шулай ук Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча карарларны һәм җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр, шулай ук Җирлек Башкарма комитетының эшен оештыру мәсьәләләре буенча күрсәтмәләр чыгара.

Җирлек башлыгы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон, башка федераль законнар нигезендә әлеге Устав компетенциясенә кертелгән башка мәсьәләләр буенча карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара.

### 73 статья. Җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган муниципаль норматив хокукый актларны, килешүләрне бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көченә керү тәртибе

1. Җирлек Советы карарлары, әгәр аларның карары белән башкасы билгеләнмәгән булса, Җирлек башлыгы имза салган көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Җирлек Советының салымнар һәм җыемнар турында норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

Җирлек Уставын кабул итү яисә әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар федераль законда, әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

2. Җирлек башлыгының, җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затларының хокукый актлары, әгәр актларның үзләре тарафыннан башкасы билгеләнмәгән булса, аларны имзалаган көннән үз көченә керә.

3. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы, гамәлгә куючысы муниципаль берәмлек булган оешмаларның хокукый статусын билгели торган, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган шартнамәләр массакүләм мәгълүмат чаралары басмаларында,

«Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы» pravo.tatarstan.ru интернет-ресурсында, «Интернет» мәгълүмат -телекоммуникация челтәренең Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы порталында «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар" бүлегендә (htpp://pravo-minjust.ru, htpp://право-минюст.рф, регистрация в качестве сетевого издания:Эл № ФС77-72471 от 05.03.2018) яисә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (httpp://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән, Җирлекнең мәгълүмат стендларында, китапханә системасы учреждениеләрендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелә.

4. Һәр муниципаль хокукый актта аның реквизитлары: исеме, аңа имза салу датасы (Җирлек Советы тарафыннан кабул ителгән хокукый актлар өчен - шулай ук аны Җирлек Советы кабул иткән дата), теркәү номеры, хокукый актны имзалаган вазыйфаи зат исеме, мөһер булырга тиеш.

5. Җирлекнең бюджет турындагы карары, аның үтәлеше турындагы хисап, җирле салымнар һәм җыемнар билгеләү турындагы карар, Җирлек Советы регламенты, Җирлек Советы, Җирлек башлыгы тарафыннан кабул ителгән башка норматив хокукый актлар, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль норматив хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларны имзалаган көннән алып җиде көн эчендә рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

6. Муниципаль сайлауларны, җирле референдумны, Җирлек Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турында, Җирлекне үзгәртү, үзгәртеп кору, Җирлек башлыгын һәм аның урынбасарын сайлау турында норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр һәм законнар нигезендә башка актлар рәсми басылып чыгарга (халыкка игълан ителергә) тиеш.

7. Законнар яисә әлеге Устав нигезендә рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) мәҗбүри булмаган норматив булмаган муниципаль хокукый актлар аларны чыгарган органнар яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары карары буенча бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) мөмкин.

8. Бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) муниципаль хокукый акт реквизитлары күрсәтелә.

Муниципаль хокукый актларны, килешүләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

- хокукый акт (килешү) текстын Җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә куелган басма массакүләм мәгълүмат чараларында яисә Җирлек территориясендә таратыла торган башка басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару. Хокукый акт текстын башка басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарганда, әлеге бастырып чыгаруның рәсми булуы хакында тамга булырга тиеш;

- Җирлек торак пунктлары территориясендә хокукый акт (килешү) текстын махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру. Әлеге стендлар һәм аларның урнашу урыннары саны Җирлек Советы тарафыннан раслана һәм Җирлектә яшәүчеләрнең муниципаль хокукый акты тексты белән каршылыксыз танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш;

- хокукый акт (килешү) текстын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру.

- хокукый акт (килешү) яисә хокукый акт проекты текстын "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында районның рәсми сайтында урнаштыру.

9. Муниципаль хокукый актны (килешүне) бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) массакүләм мәгълүмат чарасы чыгу датасы яисә тиешле актны (килешүне) игълан итү датасы турында белешмәләр күрсәтелергә тиеш, алар актны тарата башлау (тарату) датасына яисә аны мәгълүмати стендта урнаштыру датасына туры килергә тиеш.

10. Муниципаль норматив хокукый актлар, шул исәптән җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән хокукый актлар рәвешендә рәсмиләштерелгән норматив хокукый актлар Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш, аны оештыру һәм алып бару Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

11. Муниципаль хокукый акт яисә җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең тулы текстын тиешле муниципаль берәмлектә таратыла торган вакытлы матбугат басмасында беренче бастырып чыгару аны рәсми бастырып чыгару булып санала.

12. Муниципаль хокукый актларны һәм җирле үзидарә органнары килешүләрен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен «Интернет» челтәре басмасыннан да файдаланырга мөмкин. Муниципаль хокукый актның тулы тексты рәсми челтәр басмасында басылып чыккан (урнаштырылган) очракта, басмада аңа теркәлгән күләмле график һәм таблицалы кушымталар китерелмәскә мөмкин.

## XII бүлек Җирлекнең икътисади нигезләмәләре

### 74 статья. Җирлекнең икътисади нигезләмәләре

1. Җирлекнең икътисади нигезен муниципаль милектәге мөлкәт, Җирлек бюджеты акчалары, шулай ук Җирлекнең милек хокуклары тәшкил итә.

### 75 статья. Җирлекнең муниципаль мөлкәте

1. Җирлек милкендә булырга мөмкин:

1) әлеге Федераль законда билгеләнгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

2) җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда, шулай ук аларга "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешендә каралган тәртиптә җирле үзидарә органнарының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт .

3) Җирлекнең, муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары эшчәнлеген тәэмин итү өчен Җирлек Советының норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән мөлкәт;

4) җирле үзидарә органы тарафыннан федераль законнар белән хәл ителгән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт.

5) Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мөлкәт.

2. Муниципаль берәмлекләрдә әлеге статьяның 1 өлеше таләпләренә туры килми торган мөлкәткә милек хокукы барлыкка килгән очракларда, әлеге мөлкәт федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда кире кайтарылырга (максатчан билгеләнешне үзгәртергә) яисә читләштерелергә тиеш.

**76 статья. Җирлекнең муниципаль мөлкәтен биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү**

1. Җирле үзидарә органнары Җирлек исеменнән Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителә торган җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль мөлкәткә мөстәкыйль ия булалар, файдаланалар һәм алар белән эш итәләр.

2. Җирле үзидарә органнары муниципаль мөлкәтне физик һәм юридик затларга, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына вакытлыча яисә даими файдалануга тапшырырга, федераль законнар нигезендә башка килешүләр кылырга хокуклы.

3. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән башкарма хакимиятнең федераль органы билгеләгән тәртиптә муниципаль мөлкәт реестрларын алып баралар.

**77 статья. Муниципаль предприятиеләр, учреждениеләр һәм хуҗалык җәмгыятьләре**

1. Җирлек муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр төзергә, үзгәртеп корырга һәм бетерергә, хуҗалык җәмгыятьләре төзүдә, шул исәптән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципальара оешмалар төзүдә катнашырга мөмкин. Муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләргә карата гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен вәкаләтле җирле үзидарә органнары гамәлгә ашыра.

2. Җирле үзидарә органнары муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр эшчәнлегенең максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели, аларның уставларын раслый, әлеге предприятие һәм учреждение җитәкчеләрен вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә, аларның эшчәнлеге турында хисапларны әлеге Уставта һәм муниципаль хокукый актларда каралган тәртиптә тыңлый.

3. Җирле үзидарә органнары Җирлек исеменнән субсидияр тәртиптә муниципаль казна учреждениеләре йөкләмәләре буенча җаваплы булалар һәм аларны үтәүне федераль законда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә тәэмин итәләр.

**78 статья. Җирлек муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары**

1. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары Җирлек Советы карарлары белән федераль законнар нигезендә билгеләнә.

2. Муниципаль мөлкәттән файдаланудан һәм хосусыйлаштырудан керемнәр Җирлек бюджетына керә.

**79 статья. Җирле үзидарә органнарының муниципаль милектәге предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм оешмаларга карата мөнәсәбәтләре**

Җирле үзидарә органнарының муниципаль милектәге предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар белән, шулай ук физик затлар белән мөнәсәбәтләре, законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, шартнамә нигезендә төзелә.

## XIII бүлек. ҖИРЛЕКНЕҢ ФИНАНС НИГЕЗЕ

### 80 статья. Җирлек бюджеты

1. Җирлекнең үз бюджеты бар.

2. Җирлек бюджеты Җирлек Советының муниципаль норматив хокукый акты рәвешендә эшләнә һәм раслана.

3. Җирлек бюджетында Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга җибәрелә торган керемнәр һәм аларга федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләре, шулай ук күрсәтелгән керемнәр һәм субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган керемнәр аерым карала.

4. Җирле үзидарә органнары Федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең шулар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә федераль дәүләт хакимияте органнарына һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына Җирлек бюджеты үтәлеше турында хисап тапшыра.

### 81 статья. Җирлектә бюджет процессы

1. Җирлек бюджетын төзү, раслау, үтәү һәм аның үтәлешен контрольдә тоту Җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан мөстәкыйль гамәлгә ашырыла. Җирлек бюджетын төзү, раслау һәм үтәү тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексы, федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.

2. Җирлек бюджеты проекты, Җирлек бюджетын раслау турында Җирлек Советы карары, аның үтәлеше турында еллык хисап, Җирлек бюджеты үтәлеше барышы һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре саны турында квартал саен белешмәләр, аларны тотуга факттагы чыгымнар күрсәтеп, рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

3. Җирле салымнар турында муниципаль норматив-хокукый актларга үзгәрешләр кертү хакында Җирлек Советының муниципаль норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәрен үзгәртүгә китерә торган чираттагы финанс елында һәм план чорында үз көченә керә торган Җирлек Советының бюджет-хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль норматив хокукый актлары Җирлек Советына чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджет турында карар проекты кертелгәнчегә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

4. Җирлек бюджеты проекты өч елга төзелә һәм раслана (чираттагы финанс елы һәм план чоры).

5. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджеты проекты Җирлекнең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында социаль-икътисадый үсеш фаразы нигезендә төзелә.

6. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджеты проекты Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә һәм аның таләпләрен үтәү белән кабул ителгән Җирлекнең Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә һәм срокларда Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм әлеге Устав нигезендә төзелә.

7. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджетлары проектларын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Россия Федерациясе Президенты юлламасы нигезләмәләре;

Россия Федерациясенең бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре (Россия Федерациясе субъектлары бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль берәмлекләрнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре);

социаль-икътисадый үсеш фаразы;

озак сроклы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр проекты);

дәүләт (муниципаль) программалары (дәүләт (муниципаль) программалары проектлары, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектлары).

8. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджеты турындагы карарда бюджет керемнәренең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет кытлыгына төп характеристикалар, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы законнарында, Җирлек Советының муниципаль хокукый актларында (бюджет турындагы карардан тыш) билгеләнгән башка күрсәткечләр булырга тиеш.

9. Җирлек бюджеты турындагы карар белән түбәндәгеләр раслана:

- Җирлек бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеге;

- Җирлекнең бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге;

- бюджет ассигнованиеләрен төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемнәре (төркемнәре һәм төркемнәре) буенча бүлү яисә чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм программага карамаган юнәлешләр буенча), чыгымнар төрләре (төркемнәре һәм төркемнәре) һәм (яисә) максатчан статьялар, (муниципаль программалар һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре) буенча, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы законы, Җирлек Советы муниципаль хокукый акты белән билгеләнгән очракларда, бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлү;

- чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет чыгымнарының ведомство структурасы;

- бюджет ассигнованиеләренең гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә җибәрелә торган гомуми күләме;

- чираттагы финанс елында һәм план чорында Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар күләме;

- план чорының беренче елына Җирлек бюджеты чыгымнарының шартлы расланган (расланган) чыгымнарының гомуми күләме (максатчан билгеләнеше булган Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджетара трансфертлар исәбенә каралган бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча) план чорының икенче елына Җирлек бюджеты чыгымнарының гомуми күләменнән кимендә 5 проценты күләмендә (Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджетара трансфертлар хисабына каралган бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча);

- чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары;

- чираттагы финанс елыннан һәм план чорыннан соң килүче елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычның югары чиге, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиге күрсәтелеп;

- Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән Җирлекләр бюджетының башка күрсәткечләре һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Җирлек Советы муниципаль норматив хокукый актлары нигезендә кабул ителгән күрсәткечләр.

10. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджеты турында карар проекты расланган бюджетның план чоры параметрларын үзгәртү һәм бюджет проектының икенче ел план чорының параметрларын өстәү юлы белән раслана.

Чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджеты турында карар проекты расланган план чоры бюджеты күрсәткечләрен төгәлләштерә һәм төзелә торган бюджетның планлаштырылган чорының икенче елы күрсәткечләрен раслый.

Җирлектә күрсәтелгән бюджетның план чоры параметрларын төгәлләштерү түбәндәгеләрне күздә тота:

- чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджеты турында карар проектын карау предметы булган күрсәткечләрне төгәлләштерүне раслау;

- Җирлек бюджеты чыгымнарының ведомство структурасының расланган күрсәткечләрен арттыруны яисә киметүне раслау яисә аңа бюджет ассигнованиеләрен Җирлек бюджетының өстәмә максатчан статьялары һәм (яки) чыгымнар төрләре буенча кертү.

11. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджеты турындагы карар проекты белән бер үк вакытта Җирлек Советына тәкъдим ителә:

- чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджетының һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

- агымдагы финанс елының узган чорыннан соң Җирлекләрнең социаль-икътисадый үсешенең якынча нәтиҗәләре һәм агымдагы финанс елына Җирлекнең социаль-икътисадый үсешенең көтелә торган нәтиҗәләре;

- Җирлекнең чираттагы финанс елына һәм план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы;

- чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджетының төп характеристикаларын фаразлау (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет кытлыгы);

- Җирлек бюджеты проектына аңлатма язуы;

- бюджетара трансфертларны бүлү методикасы (методикалары проектлары) һәм исәпләре;

- чираттагы финанс елы ахырына һәм план чорының һәр елы ахырына муниципаль бурычның югарыгы чиге;

- агымдагы финанс елына бюджетның көтелгән үтәлешен бәяләү;

- Җирлек Советы, Ревизия комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән әлеге органнарның башкарма комитет белән каршылыклары барлыкка килгән очракта, тапшырыла торган бюджет сметалары проектлары;

- Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексында һәм әлеге Уставта билгеләнгән башка документлар һәм материаллар.

Бюджет турындагы карар белән расланган очракта, муниципаль программалар һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү турында карар проектына муниципаль программалар паспортлары теркәп тапшырыла.

Бюджет турында карар проектында бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлгән кушымта булмаса, бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлгән кушымта бюджет турындагы карар проектына аңлатма язуына кушымта составына кертелә.

12. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджеты проектын төзү Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә кабул ителә торган федераль законнар нигезендә Җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

13. Җирлек башкарма комитеты чираттагы финанс елына һәм план чорына җирлек бюджеты турындагы карар проектын агымдагы елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча Җирлек Советы каравына кертә.

14. Җирлек Советының муниципаль норматив хокукый акты белән билгеләнгән Җирлек бюджеты турындагы карар проектын карау һәм раслау тәртибе бюджет турындагы карарның чираттагы финанс елның 1 гыйнварыннан үз көченә керүен, шулай ук күрсәтелгән карар белән Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1841 статьясы нигезендә күрсәткечләрне һәм характеристикаларны раслауны күздә тотарга тиеш.

15. Җирлек бюджеты турындагы карар, әгәр Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм (яисә) Җирлек бюджеты турындагы карар белән башкасы каралмаган булса, финанс елының 1 гыйнвардан үз көченә керә һәм 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

Җирлек бюджеты турындагы карар билгеләнгән тәртиптә имзаланганнан соң ун көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

16. Җирлекнең җирле үзидарә органнары Җирлек бюджетының баланслылыгын һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салу, бюджет процессын гамәлгә ашыру, муниципаль бурыч дефициты, күләме һәм структурасы, Җирлекнең бюджет йөкләмәләрен үтәү буенча Татарстан Республикасы законнарының һәм федераль законнарның үтәлешен тәэмин итә.

17. Җирлек бюджеты керемнәре Россия Федерациясенең бюджет законнары, салымнар һәм җыемнар турындагы законнар һәм башка мәҗбүри түләүләр турындагы законнар нигезендә төзелә.

18. Җирлек бюджеты чыгымнары Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган рәвешләрдә гамәлгә ашырыла.

19. Дәүләт хакимиятенең федераль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен финанслауга билгеләнү, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очраклардан тыш, рөхсәт ителми.

20. Муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.

21. Җирле бюджет проекты, җирле бюджетны раслау турындагы карар, аның үтәлеше турындагы еллык хисап, җирле бюджетны үтәү барышы һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең саны турында квартал саен бирелә торган белешмәләр, аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнарны күрсәтеп, рәсми басылып чыгарга тиеш.

**82 статья. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар**

1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 05 маендагы 44-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар Җирлек бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

**83 статья. Гражданнарның үзара салым акчалары**

1. Гражданнарның үзара салым акчалары дигәндә гражданнарның җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен гамәлгә ашырыла торган бер тапкыр түләүләре аңлашыла. Гражданнарның үзара салымы тәртибендә түләүләр күләме, саны җирлек составына керә торган торак пункт (җирлек составына керә торган торак пункт) халкының гомуми саныннан (яисә аның территориясенең бер өлеше) 30 проценттан артмаган һәм түләүләр күләме киметелергә мөмкин булган аерым категорияләрдән тыш, җирлек составына керә торган торак пункт) халкы өчен бертигез дәрәҗәдә билгеләнә.

2. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән түләүләрне кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда, ә "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 1 өлешенең 4, 4_1 һәм 4_3 пунктларында каралган очракларда, гражданнар җыенында хәл ителә.

**84 статья. Инициатив проектларны гамәлгә ашыруны финанс ягыннан һәм башкача тәэмин итү**

1. "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 26_1 статьясында каралган инициатив проектларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү чыганагы булып, муниципаль берәмлекнең тиешле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында бирелгән Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан инициатив түләүләр һәм (яисә) бюджетара трансфертлар күләмнәрен исәпкә алып, инициатив проектларны гамәлгә ашыруга җирле бюджет турында карар белән каралган бюджет ассигнованиеләре тора.

2. Инициатив түләүләр дигәндә, конкрет инициативалы проектларны гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе законнары нигезендә ирекле нигездә түләнә торган һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә гражданнарның, шәхси эшкуарларның һәм төзелгән юридик затларның җирле бюджетка күчерелә торган акчалары аңлашыла.

3. Инициатив проект гамәлгә ашырылмаган очракта, инициатив түләүләр аларны җирле бюджетка күчергән затларга (шул исәптән оешмаларга) кайтарылырга тиеш. Инициатив проектны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча инициатив проектны гамәлгә ашыру максатларында файдаланылмаган инициатив түләүләрнең калган өлеше барлыкка килгән очракта, күрсәтелгән түләүләр аларны җирле бюджетка күчергән затларга (шул исәптән оешмаларга) кайтарылырга тиеш.

Җирле бюджетка акча күчергән затларга (шул исәптән оешмаларга) кире кайтарылырга тиешле инициатив түләүләр суммаларын исәпләү һәм кире кайтару тәртибе вәкиллекле органның (вәкиллекле орган вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы гражданнар җыены карары) норматив хокукый акты белән билгеләнә.

4. Инициатив проектларны гамәлгә ашыру шулай ук кызыксынган затларның ихтыярый мөлкәти һәм (яисә) хезмәти катнашулары рәвешендә дә тәэмин ителергә мөмкин.

## 85 статья. Җирлекнең муниципаль бурычлары

1. "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 2661 статьясында каралган инициатив проектларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү чыганагы булып җирле бюджет турындагы карарда каралган бюджет ассигнованиеләре, шул исәптән муниципаль берәмлекнең тиешле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында бирелгән Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан инициатив түләүләр һәм (яисә) бюджетара трансфертлар күләмнәрен исәпкә алып төзелгән акчалар тора.

2. Муниципаль бурыч алуларны Җирлек исеменнән гамәлгә ашыру хокукы Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Җирлекнең башкарма комитетына карый.

## 86 статья. Җирлекнең җирле бюджетын үтәү

1. Җирлекнең җирле бюджетын үтәү Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Җирлек бюджеты касса һәм ведомство буйсынуындагы чыгымнар бердәмлеге нигезендә башкарыла.

3. Җирлек бюджеты үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү, бюджет акчаларын алучыларның шәхси счетларын ачу һәм алып бару Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Җирлек бюджетын үтәү Җирлек халкының җыелма бюджет бүленеше һәм Җирлекнең касса планы нигезендә оештырыла.

### 87 статья. Бюджет хисабы. Җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисап

1. Җирлекнең бюджет хисабы еллык.

2. Җирлекнең бюджет хисабы бюджет акчаларының тиешле баш администраторларының җыелма бюджет хисабы нигезендә Җирлек башкарма комитеты тарафыннан төзелә.

3. Җирлекнең бюджет үтәлеше турында еллык хисап Җирлек Советы карары белән расланырга тиеш.

4. Җирлек бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисап, аны Җирлек Советына тапшырганчы, тышкы тикшерү узарга тиеш, ул бюджет акчаларының баш администраторларының бюджет хисаплылыгын тышкы яктан тикшерүне һәм Җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләүне үз эченә ала.

Җирлек Советының бюджет үтәлеше турында еллык хисабын тышкы тикшерү, Россия Федерациясе Бюджет кодексының һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының таләпләрен үтәү белән Җирлекнең Ревизия комиссиясе яисә Җирлек Советы тарафыннан муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Җирлекнең башкарма комитеты аңа бәяләмәне әзерләү өчен Җирлекнең бюджеты үтәлеше турында хисапны агымдагы финанс елының 1 апреленнән дә соңга калмыйча тапшыра. Җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләү Бюджет акчалары баш администраторларының еллык бюджет хисабының еллык бюджет тикшерүе күрсәткечләре нигезендә 1 айдан артмаган срокта уздырыла.

6. Ревизия комиссиясе тарафыннан Җирлек Советына Җирлек бюджетының үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә Җирлекнең башкарма комитетына бер үк вакытта юллау белән тапшырыла.

7. Ел саен, агымдагы финанс елының 1 маеннан да соңга калмыйча, Җирлек башкарма комитеты, хисап финанс елы өчен җирлек бюджеты үтәлеше турында Җирлек Советы карары проектын теркәп, хисап финанс елы өчен җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисапны, Җирлек бюджеты үтәлеше турындагы башка бюджет хисабын һәм Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган башка документларны Җирлек Советына тапшыра.

8. Җирлек Советы Җирлек бюджетының үтәлеше турында еллык хисапны карау нәтиҗәләре буенча Җирлек бюджетының үтәлеше турында еллык хисапны раслау яисә кире кагу турында карар кабул итә.

Җирлек бюджетының үтәлеше турында еллык хисап Җирлек Советы тарафыннан кире кагылган очракта, ул күрсәткечләрне дөрес түгел яисә тулы чагылдыру фактларын бетерү һәм 1 айдан артмаган срокта кабат тапшыру өчен кайтарыла.

9. Финанс елы өчен Җирлек бюджеты үтәлеше турында хисап Җирлек бюджеты үтәлеше турындагы карар буенча Җирлек бюджеты керемнәренең, чыгымнарының һәм кытлыгының гомуми суммасы күрсәтелеп раслана.

Финанс елында җирлек бюджеты үтәлеше турында хисапта Җирлек Советы карарына аерым кушымталар белән түбәндәге күрсәткечләр раслана:

- бюджетлар керемнәрен классификацияләү кодлары буенча Җирлек бюджеты керемнәре;

- керем төрләре кодлары, дәүләт идарәсе секторының бюджет керемнәренә карый торган операцияләрен классификацияләү буенча Җирлек бюджеты керемнәре;

- Җирлек бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенчаҖ ирлек бюджеты чыгымнары;

- бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча Җирлек бюджеты чыгымнары;

- бюджетлар кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча Җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары;

- бюджетлар кытлыгын финанслау чыганаклары төркемнәре, төркемчәләре, статьялары, кодлары буенча Җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары.

### 88 статья. Муниципаль финанс контроле

1. Җирлек Советы түбәндәге финанс тикшерүе рәвешләрен гамәлгә ашыра: бюджет турындагы карарлар проектларын тикшерү һәм раслау барышында алдан контроль; бюджет турындагы карарлар проектларын тикшерү һәм раслау барышында агымдагы контроль; Җирлек Советы утырышларында бюджет үтәлешенең аерым мәсьәләләрен карау барышында агымдагы контроль; бюджет үтәлеше турындагы хисапны карау һәм раслау барышында аннан соңгы контроль; шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә контрольнең башка рәвешләре.

2. Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә контрольнең башка рәвешләре.

Җирлек Советы финанс контролен Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезләмәләре нигезендә гамәлгә ашыра.

2. Бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә тышкы муниципаль финанс контроле Җирлекнең Ревизия комиссиясенең контроль эшчәнлеге булып тора.

3. Бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә эчке муниципаль финанс контроле Җирлек Башкарма комитетының органнары (вазыйфаи затлары) булган муниципаль финанс контроле органнарының контроль эшчәнлеге булып тора.

4. Алдан тикшерү Җирлекнең җирле бюджетын үтәү барышында бюджет бозуларын кисәтү һәм булдырмау максатларында башкарыла.

5. Аннан соңгы контроль аларны үтәүнең законлы булуын, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның дөреслеген билгеләү максатларында Җирлек бюджетын үтәү нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла.

## XIV БҮЛЕК. Җирлек Уставын кабул итү. Гамәлдәге Уставка үзгәрешләр кертү

### 89 статья. Җирлек Уставы проектын әзерләү, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү тәртибе

1. Җирлек Уставы проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар Җирлек Советына Җирлек башлыгы, Җирлек Советы депутатлары, территориаль

иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициатив төркемнәре тарафыннан кертелергә мөмкин.

2. Җирлек Уставы проектын, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар проектын әзерләү өчен Җирлек Советы карары белән махсус комиссия төзелергә мөмкин. Әлеге комиссия эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белгечләре, экспертлар чакырылырга мөмкин.

3. Җирлек Уставы проекты, Җирлек Уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, Җирлек Уставын кабул итү, Җирлек Уставына үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләне караганчы 30 көннән дә соңга калмыйча әлеге Устав проекты, муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук гражданнарның аны тикшерүдә катнашу тәртибен Җирлек Советы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) белән бергә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Җирлек Уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук муниципаль берәмлек уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясе субъекты конституциясе (уставы) яисә законнары нигезләмәләрен әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында үзгәртү кертелгән очракта, гражданнарның аны тикшерүдә катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми.

4. Уставка үзгәрешләр Уставта беркетелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне һәм аларны хәл итү вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясенә һәм федераль законнарга туры китерү максатларында гына кертелү очракларыннан тыш, Җирлек Советы утырышында Җирлек Уставы проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча аларны карау алдыннан әлеге Устав нигезендә гавами тыңлаулар үткәрелә.

### 90 статья. Җирлек Уставын кабул итү, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү тәртибе

1. Җирлек Уставы проектын, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар проектын карау Җирлек Советы тарафыннан Җирлек Советы регламенты нигезендә кимендә ике укылышта гамәлгә ашырыла.

2. Җирлек Уставы проектын, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар проектын беренче укылышта кабул иткәннән соң, әлеге проект Җирлек башлыгы тарафыннан Җирлек Советы депутатларына, хокук чыгару инициативасы хокукына ия башка субъектларга төзәтмәләр кертү өчен җибәрелә.

3. Җирлек Уставы, Җирлек Советы карарына үзгәрешләр кертү турында карар Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санынннан өчтән икесе тавышы белән кабул ителә.

4. Муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт белән җирлек уставын яңа редакциядә бәян итү рөхсәт ителми. Бу очракта муниципаль берәмлекнең яңа уставы кабул ителә, ә муниципаль берәмлекнең элек гамәлдә булган уставы һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актлар муниципаль районның яңа уставы үз көченә кергән көннән үз көчләрен югалткан дип таныла.

### 91 статья. Җирлек Уставының үз көченә керү тәртибе, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар

1. Җирлек Уставы, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында Җирлек Советы карары, алар кабул ителгәннән соң, Җирлек башлыгы тарафыннан федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен муниципаль

берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органына җибәрелә.

2. Әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында Җирлек Советы карары, алар дәүләт теркәвенә алынганнан соң рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм алар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткергәннән) үз көченә керә.

Җирлек башлыгы муниципаль берәмлек Уставын, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актны муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан кайткан көннән соң җиде көн эчендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) тиеш.

3. Муниципаль берәмлек Уставына кертелгән һәм җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүлешү (муниципаль берәмлек уставын федераль законнарга туры китерү, шулай ук җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының вәкаләтләрен, вәкаләтләре срокларын, сайланулы вазыйфаи затларын сайлау тәртибе үзгәрү очракларыннан тыш) муниципаль берәмлек уставына күрсәтелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актны кабул иткән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре срогы чыккач үз көченә керә, ә муниципаль районның вәкиллекле органы формалашкан очракта-муниципаль берәмлек уставына күрсәтелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актка кул куйган муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләре срогы чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр муниципаль хокукый акт белән кертелә, ул түбәндәгечә рәсмиләштерергә мөмкин:

1) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының аның рәисе һәм муниципаль берәмлек башлыгы яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе вәкаләтләрен башкаручы муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан имзаланган карары белән;

2) вәкиллекле орган кабул иткән һәм муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан имзаланган аерым норматив хокукый акт белән. Бу очракта әлеге хокукый актта аны кабул итү турында вәкаләтле орган карарының реквизитлары күрсәтелә. Вәкиллекле органның әлеге карарына муниципаль берәмлек Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы күчмә нигезләмәләрне һәм (яисә) нормаларны кертү рөхсәт ителми.